Чыныктырды хезмәт,
кара алтынга рәхмәт!

Рәвил Фәйзи улы Шибаев
Равиль Файзиевич Шибаев

# ЧЫНЫКТЫРДЫ ХЕЗМӘТ, КАРА АЛТЫНГА РӘХМӘТ!

Шигырьләр
3нче җыентык



Алабуга
2024

**Мин халыктан ерак түгел,**
**Дәрәҗәм юк дигән- "данлыклы".**
**Халыкныкы, бары халыкныкы,**
**Бу исемнән ни бар кыйммәтле?**
**Бу исем бик миңа кыйммәтле!**
**Шуңа күрә Сезгә рәхмәтле!**

***(Р.Ф.Шибаев, 2024 ел)***



**Печатная и электронная версия данного издания являются собственностью автора**
**Шибаева Равиля Файзиевича.**
**Её распространение без согласия автора запрещается!**

# Об авторе сборника.

2024 год – юбилейный для автора.

2023 год – трижды юбилейный для нефтяной отрасли Татарстана:

80 лет назад начата промышленная добыча нефти в Татарстане,

75 лет как открыто Ромашкинское месторождение,

30 лет как начал свой трудовой путь, путь Нефтяника- Равиль Файзиевич Шибаев.

За 30 лет работы в ПАО «Татнефть» занимал почти все основные профессии, которые связаны с добычей «черного золото» и требуют преданности к своей профессии, профессионализма. Равиль Файзиевич начал свою трудовую деятельность в НГДУ «Прикамнефть» 5 октября 1993 года оператором 2 разряда по добыче нефти и газа ЦДНГ-1, (за 20 лет работы оператором добычи нефти и газа вырос до должности оператора по добыче нефти и газа 6 разряда), был наставником для 17 начинающих нефтяников, которые делали под его руководством первые шаги в профессию, которые трудятся в Компании до сих пор и благодарны своему наставнику. Его объекты всегда были образцовыми. 10 лет обслуживал добывающие скважины Первомайского месторождения, групповые замерные установки(ГЗУ) №№24,16,16А.

Потом предложили самый ответственный объект, и Равиль 10 лет качественно выполнял свои трудовые обязанности: обслуживал добывающие скважины и Групповые замерные установки(ГЗУ) №№42,43,44,45 Бондюжского месторождения НГДУ «Прикамнефть», ПАО «Татнефть» на гидротехническом сооружений с отдельно стоящими спецоснованиями, где размещены скважины.

Конструкция дамбы представляет собой подкову, которая упирается основаниями в коренной берег. Дамба служит автодорогой, площадкой для скважин, нефтепроводов, линией связи и электроэнергии. В 1993 году начальником цеха по добыче нефти и газа №1 был Васильев Л.Ф., который всегда и в любую погоду мог приехать (а если не было дорог на лыжах) с проверкой и всегда Равиль встречал его около устья скважины, за работой. Через три года таких проверок, Леонид Филиппович сказал: «Молодец! Видно, что ты старательный парень, такие нам и нужны!». Вспоминая

о ЦДНГ-1 Равиль Файзиевич говорит, что это родной коллектив, как семья.

При участии Шибаева Р.Ф. добыто сотни миллионов тонн нефти, пройдено сотни тысяч километров дорог.

Затем работал диспетчером пульта управления и инженером-технологом этого же цеха.

Далее продолжил свою трудовую деятельность инженером в службе по борьбе с коррозией и охране природы. Начальник службы Халиков Рашид Габдулхакович после собеседования показал рабочее место, познакомил с коллегами.

Потом получил должность ведущего инженера (по защите от коррозии и борьбе с осложнениями) отдела транспортировки нефти, газа и воды НГДУ «Прикамнефть».

С августа 2020 года работает в должности ведущего специалиста (по промышленной безопасности, охране труда и окружающей среды) в НГДУ «Прикамнефть» СП «Татнефть-Добыча» ПАО «Татнефть». Его девиз: «Человек-это часть природы, в которой всё взаимосвязано. Поэтому, беречь и охранять её нам необходимо!».

Нефтегазодобывающее управление «Прикамнефть» является уникальным предприятием, его силами разрабатываются месторождения на территории реликтовых Шишкинских лесов, в национальном парке «Нижняя Кама», в акватории водохранилища Нижнекамской ГЭС, что налагает на коллектив особую ответственность. В этих условиях работники управления уделяют самое пристальное внимание вопросам экологической безопасности.

Коллектив НГДУ всегда отличался трудоспособностью, профессионализмом, умением достойно выходить из сложных ситуаций.

Главное достояние предприятия-люди, такие люди как наш главный герой-Равиль Шибаев.

За время работы в ПАО «Татнефть» зарекомендовал себя как грамотный, инициативный, ответственный работник. Личным примером демонстрирует активное участие в жизни Компании, внедрению современного оборудования, применению новых технологий, полное и постоянное соблюдение требований промышленной безопасности, охраны труда и окружающей среды.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


По итогам работы за 2022 год по ПАО «Татнефть» занял 2 почетное место по своему направлению. Постоянно работает над повышением своей профессиональной компетентности, результатом которых являются награды:

Занесен на «Доску Почета» НГДУ «Прикамнефть» (Решение №85 от 10.08.1999 г.).

За заслуги перед ОАО «Татнефть», высокий профессионализм и многолетнюю деятельность на благо общества награжден благодарностью генерального директора ОАО «Татнефть» (№ 205/60 от 31.07.2002 г.).

За большой личный вклад в развитие топливно-энергетического комплекса и многолетний добросовестный труд награжден почетной грамотой Министерства энергетики РФ (№ 70п от 30.06.2016 г.).

За многолетний плодотворный труд, активную работу в профсоюзе награжден почетной грамотой Профсоюзного комитета МПО Группы предприятий «Татнефть» (от 05.02.2019 г.).

За участие в общественной жизни комплекса награжден Благодарственным письмом директора комплекса МАОУ «Полилингвальный образовательный комплекс «Адымнар-Алабуга» ЕМР РТ (от 26.05.2023г.).

За заслуги перед профсоюзным движением награжден Почетным знаком профсоюзного комитета Татнефть Профсоюз (Постановление №42 от 19.01.2024 г.).

*С коллегами по работе отношения хорошие, дружеские, пользуется заслуженным уважением в коллективе. Не имеет вредных привычек, ведет здоровый образ жизни. Активно участвует в спортивных и культурно-массовых мероприятиях НГДУ, а также участвует и побеждает в конкурсах, организованных профсоюзным комитетом ПАО «Татнефть». В свободное от работы время пишет стихи на татарском языке и статьи в корпоративные газеты: «Хәзинә» и «Нефтяник Прикамья». В 2021 году были изданы два авторских сборника стихотворений, многие из которых посвящены родному НГДУ «Прикамнефть» и нефтяной тематике, любимой Республике, природе, коллегам и друзьям. За прекрасные стихи коллеги его называют: «Прикамский Тукай». Равиля Файзиевича часто показывают по местному телевидению,*

*журналисты берут интервью на рабочем месте, приглашают в дворец культуры города Елабуга, на встречи с жителями города. С 2001 года является донором в Республиканском центре крови города Казань, общее количество безвозмездных кровоотдач – 39, сдано – 16 литров крови. Сколько спасенных жизней?!*

*С 2012 года является председателем многоквартирного дома города Елабуга, также состоит в команде добровольцев народной дружины ПАО «Татнефть» (№790 от 25.03.2022г.). С 24.02.2011 г. является членом партии «Единая Россия». Воспитывает сына Алмаз – ученика 9Б класса МАОУ «Полилингвальный образовательный комплекс «Адымнар-Алабуга» ЕМР РТ.*

*Талантливый человек талантлив во всем!*

*Потому что, Равиль Файзиевич – работник Компании №1 в Республике Татарстан, который с гордостью несет звание-Нефтяник ПАО «Татнефть» имени В.Д.Шашина.*

***(Материал из корпоративной газеты «Нефтяник Прикамья»).***

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Нефтьче гимны.

Безгә кирәк яхшы үзгәрешләр,
Кирәк бары алга барырга.
Нефтьчеләр безнең булдыралар,
Дан җырлыйбыз һәркөн аларга.

Мин яратам сине, Татар нефте,
Кара алтын-Халык байлыгы.
Көч бирәсең үрләр яулар өчен,
Куандыра синең барлыгың.

Яңа йортлар, юллар төзеләләр,
Чәчәк ата безнең Республика.
Кара Алтын үз өлешен кертә,
Рәсәй дигән бөек дәүләткә.

Мин яратам сине, Татар нефте,
Минем һөнәр-шуңа яратам.
Хезмәттәшләр бездә уңган, тырыш,
Булган өчен сине яратам!

Без беренче, без-Татар милләте,
Сынау үткән бик күп эшләрдә.
Без барабыз алга, бары алга,
Ышанычлар безнең яшьләрдә!

Мин яратам сине, Татар нефте,
Кара алтын-Халык байлыгы.
Көч бирәсең үрләр яулар өчен,
Куандыра синең барлыгың!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Туган көн.

Ап-ак карлар яуганда,
Туганмын матур җирдә.
Чишмә суын эчкәнмен,
Бик тиз үсеп җиткәнмен.

Әле генә унҗиде яшь иде,
Кай арада үтте бу гомер?
Бу зарлану түгел тормышыма,
Рәхмәт әйтәм, булганы шөкер!

Танышларым үзгәрмисең диләр,
Шулай ук яшь, гади һәм тырыш.
Үз-үземә бары мин ышандым,
Өйрәтә ул дуслар, бу-тормыш!

Искә алган өчен рәхмәт дуслар,
Сезгә дә мин телим уңышлар!
Гафу, гафу, гафу диеп әйтәм,
Булган булса миндә ялгышлар.

Әле генә унҗиде яшь иде,
Кай арада үтте бу гомер?
Үкенмим мин, яхшы дуслар таптым,
Сез булганга бүген мин шөкер!
Сез булганга дуслар, мең шөкер!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Яңа Ел кичендә.

Хыялланып алыйк дуслар,
Яңа Елның кичендә.
Кыш Бабай килгән икән диеп,
Җәй көненең кичендә.

Кар кызын ул киендергән,
Ромашкалы күлмәктән.
Бүләкләрен ул чыгарган,
Сихри көчле чүлмәктән.

Су анасы хәтта чыккан,
Кыш Бабайны карарга.
Алтын тарагын күрсәтеп,
Сачләрен ул тарарга.

Шүрәле дә ерак түгел,
Күзәткән бу гамәлне.
Килә алмаган бары тик,
Гаепләгән Былтырны.

Бармакларын кыстырган бит,
Барыбыз да беләбез.
Былтыр кыскан Шүрәлене,
Килегез, коткарыгыз.

Җиләкле, матур аланда,
Йөргәннәр боланнарда.
Беренче тапкыр күргәннәр,
Кар Кызын болыннарда.

Кар Кызы пешкән җиләктән,
Авыз итеп караган.
Ул аптырап сорау биргән:
Бу ризык бит-балан?

Шулай дуслар, үз хәленә,
Кайтарыйк Яна Елны.
Кыш Бабай да, Кар Кызы да,
Килсеннәр Яна Елны!

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Ничек язасың?

Син ничек язасың диләр,
Матур шигырь юлларын?
Сулдан-уңга язам дим мин,
Кулымда бар каләмем.

Җавап бирәм мин шаярып,
Җитди түгел сорауга.
Күпләр хәтта тынып кала,
Минем кырыс карауга.

Син ничек язасың диләр,
Кайдан илһам аласың?
Сүзне-сүзгә ничек ялгап,
Туры юлдан барасың?

Сораулар күп, әмма ләкин,
Җавап табуы кыен.
Ярдәм итә һава, сулар,
Урмандагы ак каен.

Шигырьләрем күңел аша,
Йөрәк аша үтәләр.
Алар мине читләп үтми,
Иртән, кичен көтәләр.

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Сугышларсыз...

Сугышларсыз тора алмый кеше,
Дөнья җитми аңа күрәсең.
Сорар идем мин шуны кешедән,
Ниләр тагын, ниләр бүләсең?

Басу кырлар, урманнар җитмиме?
Әллә инде җитми шул байлык?
Халык канын коеп, тагын, тагын,
Аңлагыз сез, бу бит наданлык!

Сугышларда бүген вафат була,
Кемнәрнеңдер газиз баласы.
Ничек икән шушы балаларны,
Үлемнәрдән алып каласы?

Кайчан туктап калырсыз икән сез?
Тыныч тормыш бүләк итәрсез?
Көчегездән әгәр дә килмәсә,
Чит илләргә качып китәрсез?

Сугышларсыз тора алмый кеше,
Тыныч тормыш аңа ярамый...
Дошманнарның сугыш кораллары,
Күпме солдатларны яралый...
Туктагыз сез, алай ярамый!!!

## 23 февраль.

Кечкенәдән уйнап үстек,
Мылтык, автомат тотып.
Армиядә без чыныктык,
Ике ел хезмәт итеп.

Тыныч тормышның бәясен,
Беләбез, әле истә...
Безнең бабайлар булдылар,
Сугышта ярты дистә.

Ачлык, ялангачлык үтеп,
Тирән ярага батып.
Кайттылар җиңеп фашистны,
Берлинга хәтле атып.

Бик күпләре ятып калды,
Авыр сугыш кырында.
Балалары ятим калды,
Кырык бишнең язында.

Кызыл Армия көченнән,
Фашистлар куркып качты.
“Пантера” һәм «Тигр»лары,
Төрле якларга очты.

Дөнья бүген тыныч түгел,
Сугышлар тормый тынып.
Тарихны да үзгәртәләр,
Илләрне булмый танып.

Бергәләшеп теләк телик,
Илгә кайгы килмәсен.
Запастагы солдатларның,
Саннары кимемәсен!

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


# Яңа Ел.

Яңа Елда “Яңа бәхет”-диеп,
Теләк тели бик күп кешеләр.
“Искесеннән” аермасын Раббым,
Аңлар мине үзем ишеләр.

Искә алсам, без кечкенә чакта,
Яңа Елны каршы алулар...
Абыйларның йонлы тунын киеп,
Мәктәп чыршысына барулар.

Кемдер аю, куян яки төлке,
Булып киенәләр иде дә...
Бу мизгелләр бүгенгедәй истә,
Бик күп еллар үтеп китсә дә.

“Вируслар” да куркытмыйлар иде,
“Өйдә генә утырыгыз”- диеп.
Кем уйлаган килер шундый көн диеп,
Йөрербез диеп, киеп битлекләр.

Еллар буе битлектә йөрибез,
Кайчан бетәр бәла белмибез.
Теләкләр бер, Яңа Елда бары,
Сау-сәламәт булыйк үзебез!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Искә алу.

Табигитьтә сине искә алып,
Елый кебек миңа, бу көндә.
Сүрәтеңә карап туктап калам,
Сагыну минем бүген күңелдә.

Күз алдыма килә синең йөзең,
Елмаюың, синең нурлы күзең.
Ачылыгын тормыш көтүләрнең,
Белгәнсеңдер ӘНИ бары үзең.

Булгансың син ӘНИ биг(е)рәк түзем,
Сигез балаң һәм дә син бер үзең.
Аш пешереп, савыт-саба юып,
Сизелмичә үткән синең гом(е)рең.

Рәхмәт ӘНИ!,-диеп әйтәм бүген,
Бик кызганыч арабызда түгел.
Көндә сине никтер көтә күңел,
Кайтарырга ләкин мөмкин түгел!
Кайтарулар безнең көчтән түгел!

## Саргайган.

Яфраклар саргайган кебек,
Кешеләрдә саргая.
Кайгылардан кайбер кеше,
Акылын хәтта җуя.

Яфраклар саргайган кебек,
Саргая кешеләрдә.
Яшь булуга карамастан,
Чал куна чәчләренә.

Яфраклар саргайган кебек,
Кешеләрдә саргая.
Вакытны туктатып булмый,
Ашыгадыр ул кая?

Бөреләнеп, яфрак ярып,
Яна яши башлагач.
Яфраклар тиздән коелды,
“Шәрә” калды ник агач?

Вакыт бара, гомер үтә,
Кайтарып булмый һич тә.
Бакыйлыкка кешеләр китә,
Агачлар яна мичтә.

## Уйланмагыз.

Яшь турында уйланмагыз,
Аяк, куллар йөргәндә.
Картайдым диеп зарланмагыз,
Йөрәккәйләр типкәндә.

Яшь турында уйланмагыз,
Сөенегез иртән, кич.
Бу дөньяда, исән чакта,
Яшәүләре сөенеч.

Яшь турында уйланмагыз,
Сөегез, сөелегез.
Бәхеттә бары яшәгез,
Көлеп торсын йөзегез.

Яшь турында уйланмагыз,
Елмаегыз, көлегез.
Яхшылыклар кылып үтсен,
Сезнең һәрбер көнегез.

Күзләрегез янып торсын,
Карамастан яшьләргә.
Шатлыкларда, шөкер әйтеп,
Язсын тагын яшәргә!

## Туган телне кирәк сакларга!

Ярлы* телле татар булсынмы ул,
Яки бүтән милләт вәкиле.
Югалмаслар бу дөньяда, ләкин,
Бик бәхетле булу икеле.

Туган телне кирәк яратырга,
Туган телне кирәк сакларга.
Кирәк булса, гомереңне биреп.
Туган телне кирәк якларга!

Туган телне кирәк акларга,
Өйрәнергә, серен сакларга.
Олы сәхнәләргә чыгып,
Матур шигырьләрен ятларга!

Туган телнең нидә икән көче?
Нидә икән аның кадере?
Тукай, Җәлил теле булган өчен,
Шуңа да ул безгә кадерле!

**Ярлы телле* - *туган татар телен оныткан, аңлый, сөйләшә белми.*

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Уятыр яхшы хәбәр!

Сугыш әле бетмәгән,
Җиңү килеп җитмәгән.
Солдатларны олы юллар,
Кайда гына илтмәгән.

Әти-әнисе догасы,
Яралардан саклаган...
Дошманнар артка чигенгән,
Ә ул алга атлаган.

Ватанны бүген саклыйлар,
Безнең кыю лачыннар.
Дөреслек бит безнең якта,
Җиңү белән кайтсыннар.

Бабайлар җиңеп кайткандай,
Алар да тиздән кайтыр.
Безне язгы бер иртәдә,
Яхшы хәбәр уятыр!

## Рәхмәт Әниләргә!

Март аеның сигезендә,
Кызларны без котлыйбыз.
Аларга чәчәкләр биреп,
Рәхмәт диеп кочаклыйбыз!

Иң беренче рәхмәтләрне,
Әйтәбез Әниләргә!
Безне табып, үстергән ул,
Хатын булган Әтигә.

Бергәләшеп наз биргәннәр,
Биргәннәр аң һәм белем.
Өйрәткәннәр туган якның,
Белсен диеп матур телен.

Язарга да өйрәткәннәр,
Өйрәткәннәр укырга.
Өйрәткәннәр өлкәннәргә,
Шәфкатьле дә булырга.

Тагын бик күп һөнәрләргә,
Көтәргә тормыш атын...
Авырлыкларны җиңәргә,
Бик күп эшләргә тагын...

Рәхмәт Сезгә Әби, Әни,
Апа һәм сеңлекәшләр!
Сигезенче март көнендә,
Сезгә безнең алкышлар!
Телибез Сезгә уңышлар!

## Белеп булмый.

Белеп булмый кешеләрнең,
Ниләр уйлавын.
Чын йөрәктән әйтәләрме,
Әллә уйнавын?

Белеп булмый кешеләрнең,
Кайчан алдавын.
Үзләренең сүзләренә,
Хуҗа була алмавын.

Белеп булмый дусларның да,
Кайчан “сатасын”.
Авыр чакта, арттан килеп,
Пычак кадасын.

Белеп булмый кешеләрнең,
Торган бәясен.
Көч табасың эндәшмәскә,
Сизеп хәйләсен.

Белеп булмый, була бары,
Ерак качарга.
Яңа тормышларны башлап,
Дуслар табарга.

## Гомер кыска.

Гомер кыска,
Шигырь мәңгелек.
Гомер кыска,
Кыл син игелек.

Искә алып,
Сине сөйләрләр.
Шигырьләрне,
Җырга көйләрләр.

Гомер кыска,
Шигырь мәңгелек.
Халкың турында,
Уйла син элек.

Искә алып,
Рәхмәт әйтерләр.
Гасырлар сине,
Истә йөртерләр.

## Тамчы тама.

Язгы көннәр,
Тамчы тама,
Кыек түбәдән.
Туктар сыман,
Бик еш типкәч,
Йөрәк тибүдән.
Кошлар кайта,
Туган якка,
Безне сагынып.
Син көтәрсең,
Килер диеп,
Әле ялынып.
Исәптә юк,
Синең янга,
Чабып барырга.
Кайнар сөю үткәнгәме,
Әллә үпкәме?
Ни өчендер,
Төшкә керми,
Минем башладың.
Исемеңне еш кабатлау,
Эшен ташладым.
Сөю үткән булгангамы?
Әллә ялгышкан?
Бозда әнә, түбәләргә,
Бик нык ябышкан.
Боз эрегән,
Кебек йөрәк,
Эрер бервакыт.
Ләкин бар(ы)да онытылган,
Үткән күп вакыт!

# Бака бакылдык.

Урам буйлап егет бара иде,
Яшел бака чыкты юлына.
Ярдәм итче, ярдәм итче диде,
Ал син мине, ал син кулыңа.
Яши икән матур бака,
Күрше сазлыкта.
Зарланып ул хәбәр бирде,
Юк бер балыкта.
Хыялланам яшәргә мин,
Матур бер күлдә.
Әйтче диде бу теләкне,
Зинһар халыкка.
Төнбоеклы чиста күлдә,
Кояш нурында.
Кызыныр идем көн буе,
Ярның кырында.
Чишмә сулы, зәңгәр күлдә,
Килә йөзәсем.
Бер ярдан, икенче ярга,
Күлне гизәсем.
Су анасын кичләр җиткәч,
Килә күрәсем.
Алтын таракларын күреп,
Ух син, диясем.
Яр буендагы талларда,
Кошлар күрәсем.
Шул кошларга бер кушылып,
Моңнар үрәсем.
Учларына алды егет,
Һәм китте күлгә.
Ярдәм итте сихри затка,
Шатлык күңелендә.
Күлгә кергәч яшел бака,
Җибәрде сөйләп.
Шатлыгыннан, көтмәгәндә,
Җырлады көйләп.

Саубуллашып бака белән,
Егет китте кайтып.
Бервакыттан туктап калды,
Таныш тавыш ишетеп.
Коткардың син мине диде,
Яман сазлыктан.
Алып калдың үлемнән дә,
Һәм дә ачлыктан.
Шул хөрмәткә әзер үзем,
Рәхмәт әйтергә.
Өч теләгең булса әгәр,
Әзер үтәргә.
Уйга батты: нинди теләк,
Теләргә икән?
Байлык әгәр дә сорасам,
Бик тиздән бетәр.
Дәүләт әгәр дә сорасам,
Көтәргә кирәк.
Депутатлар бүген бик күп,
Кәнәфи сирәк.
Саулыктан да кыйммәт нәрсә,
Юктыр дөньяда.
Телә диде бары саулык,
Миңа җомгада!
Бу сүзләргә яшел бака,
Бик тә сөенде.
Өч секунд булды дигәндә,
Кызга әверелде.
Озын чәчле, кара күзле,
Елмаеп тора.
Егет белән бу матур кыз,
Гаилә кора.
Күптә үтми, уллары һәм,
Кызлары туа.
Бу шигырьнең азагында,
Никах, туй була!

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Исеңдәме Әти?

Әти! Әти!
Исеңдәме Әти?
Мин кечкенә чакта,
Уйный идек икәү качышлы?
Эзли идең мине,
Юри генә,
Күрмәмешкә инде салышып.
- Бирешәмен,
Кая качтың?
Табып булмый сине,
Берничек.
Белә идең үзең,
Ишек артында мин,
Тында алмый,
Сине күзәтәм.
Шундый матур,
Истәлекләр калган өчен,
Хөрмәтлим мин сине,
Үз итәм.
70 яшьлек юбилееӊ бүген,
Бер дә биреп булмый,
Андый яшь.
Син яшь әле,
һәм син янда чакта,
Мин дә тоям үземне бик яшь.
Нинди матур тормыш мизгелендә,
Янда булса Әти-Әниләр,
Соң аңлыйбыз күп чакта шуны без,
Алар безгә бәхет телиләр.
Тормыш матур булса янда,
Әгәр туганнар.
Рәхмәт әйтә Әти сиңа бүген,
Барлык туганнар!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Зарланабыз.

Зарланабыз авыр диеп,
Безнең тормышлар.
Карап торам, чит илләрдән,
Кайтты танышлар.

Зарланабыз авыр диеп,
Кыйммәт ризыклар.
Азыклар белән шыплап,
Тулган чүплекләр.

Зарланабыз вакыт юк диеп,
Гамәл кылырга.
Сәбәпләр һәрчак эзлибез,
Читтә калырга.

Зарланабыз, зарланабыз,
Иртән һәм кичен.
Зарланмады әти-әни,
Элек ни өчен?

Кунакларга йөрешмибез,
Без инде күптән.
Көтәбез, үзе килер туганлык диеп,
Яки төшәр күктән.

## Соңгы юл...

Яши кеше-укый, эшли,
Аннан гаилә кора.
Безнең тормыш бик күп чакта,
Мәшәкатьләрдән тора.

Тырышабыз, булсын диеп,
Эшлибез армый-талмый.
Кичләр җиткәч, өйгә кайткач,
Хәлебез бер дә калмый.

Гаиләңдә сине көтеп,
Торучылар булганда.
Бу арулар бик тиз үтә,
Сау-сәламәт булганда.

Тормыш бара, гомер үтә,
Балалар үсеп җитә.
Балаларның балалары,
Безне тиз куып җитә.

Шулай матур яшәгәндә,
Өзелә тормыш юллары...
Озаталар соңгы юлга,
Кызлары һәм уллары.

Шундый авыр вакытларда,
Дуслар, туганнар кирәк...
Юксынырбыз Абый, сине,
Сагынып тибәр йөрәк.

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Мин ышанам.

Мин ышанам, ничектер башкалар,
Хыяллар тормышка ашалар.
Мин ышанам, ничектер башкалар,
Исән-сау булсын тик башкайлар.

Мин ышанам, ничектер башкалар,
Хыяллар тормышка ашалар.
Киләчәк якты ул, ул матур,
Һәр көнне бик якты таң атар.

Мин ышанам, ничектер башкалар,
Хыяллар тормышка ашалар.
Төннәрен йолдызлар аталар,
Таңнарда сайрашып кошчыклар очалар.

Мин ышанам, ничектер башкалар,
Хыяллар тормышка ашалар.
Ышанмыйча булмый хыялларга,
Киләчәккә безне илтә алар.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Көз.

Көзләр тагын нигә килдең диеп,
Көзгә күпләр сорау бирәләр.
Сөюләрнең үтеп киткәненә,
Гаепне дә аннан күрәләр.

Мәхәббәтне бик тиз көзләр җиңгәч,
Кышлар җиткәч эшләрсез ниләр?
Өшетерсез кайнар йөрәкләрне,
Язлар җиткәч соң шул, соң булыр.

Яңгыр ява, салкын көннәр килде,
Яфракларда җиргә коелды.
Кошлар җылы якка юнәлеште,
Җир Анабыз муллык өләште.

Көзләр безне кышка әзерлиләр,
Әзерлик без җылы киемнәр.
Алтын көзнең нинди гаебе бар?
Күп калмады, явар ап-ак кар.

## Сүзләре дә шифалы.

Матур дөньяга туабыз,
Табиблар ярдәмендә.
Алар бик күп ярдәм итә,
Яшәү дәверләрендә.

Теш сызласа йөгерәбез,
“Ярдәм итегез”- диеп.
Күптә үтми без чыгабыз,
Матур елмаеп, көлеп.

Суык тисә, вирус килсә,
Булмый алардан башка.
Биш минут булды дигәндә,
Җиңеллек килә башка.

Шифалы аларның сүзе,
Дарусыз да дәвалый.
“Туйга хәтле төзәлер”- диеп,
Алар сүзен тәмамлый.

Бик җаваплы һөнәрегез,
Гомерне хәл итәсез.
Табиб исемен югары,
Сез күтәреп йөртәсез.

Шигырь юлларына салдым,
Мин бүген рәхмәтемне.
Барлык табиблар ишетсен,
Минем зур хөрмәтемне!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Тырышырлар...

Бик нык торсаң аягыңда,
Тырышырлар чалырга.
Әгәр дә шул чак егылсаң,
Әзер алар чагарга.

Бик нык торсаң үз сүзеңдә,
Ялган белән "җиңәрләр".
Белмиләр, мине җиңәргә,
Җитәрме икән егәрлек?

Бик нык кешелекле булсаң,
Башыңа да менәрләр.
Менеп җиттем дигәндә тик,
Очып төшәр "җүләрләр".

Бик нык үзем, бик тә түзем,
Көчем сезгә җитәрлек.
Күп "бөгәргә" тырыштылар,
Көче моның бетәр диеп.

Бик нык булуның сәбәбе,
Авыл тәрбиясендә.
Бала барысын күреп үсә,
Үзенең гаиләсендә.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Тормыш.

Тормыш көтәм, гомер юлын үтәм,
Үз тормышым минем, кыйбылам.
Авыр чакта түзәм, чыныктым мин,
Өйгә кайтып аннан, егылам.

Тормыш көтәм, гомер юлын үтәм,
Чабам таңнан мин кичкә кадәр.
Кулланалар бары, сизәм, көтәм,
Бер булмаса булыр бер кадер.

Тормыш көтәм, сынауларны үтәм,
Үземнән соң кала диеп балам.
Бер егылсам, торам алга барам,
Тормыш тәҗрибәсен шулай мин алам.

Тормыш көтәм, бәлки ул да көтә,
Ниләр тагын эшләр икән диеп.
Кайгы килсә елыйм туктый алмый,
Шатлык килсә җырлыйм мин биеп.

Тормыш көтәм, гомер юлын үтәм,
Тормыш көтү авыр эш икән.
Бер җайланыр дуслар әле тормыш,
Өмет итәм, итәм, итәм, итәм,
Шул вакытны көтәм, көтәм, көтәм!

## Икейөзле.

Икейөзле кешеләрне күрсәм,
Ни әйтергә белми торам мин.
Дөрес юлга чыгарырга теләп,
Бик күп уйлар башта корам мин.

Дөрес сүзне әйтергә дә алар,
Бик күп чакта куркып калалар.
Туры биргән сорауларга җавап,
Алуы да авыр алардан.

Кемнәр шулай куркытты аларны?
Үз фикерен әйтә белмиләр.
Акны-кара, караны-ак диеп,
Алар ала начар “билгеләр”.

Дәшми-тынмый тик яши бирәләр,
Әйтерсең лә алар яшь бәрән.
Сезне дөрес юлга чыгарырга,
Аңлатырга сезгә сүз бирәм.

Фашист бәреп безгә кергән чакта,
Шундый булган булса бабайлар?
Ирек булмас иде бүген безгә,
Булыр иде кулда богаулар.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Ял көнендә.

Эш атнасының беткәнен,
Көтә сагынып йөрәк.
Ниләр аңа җитми икән,
Тагын ни аңа кирәк?

Җомга көненең кичендә,
Шашынып тибә йөрәк.
Кемдер шәрабка табына,
Ә күпләр ала көрәк.

Ял көнендә үз бакчаңда,
Үткәрүгә ни җитә?
Яшелчә түтәлләрендә,
Ял көне үтеп китә.

Яңа эш атнасына мин,
Әзер яңа көч белән.
Ә кемнәр шәраб эчтеләр,
Авыр аларга, беләм.

Аек акыл, баш авыртмый,
Эшләнә эштә эшләр.
Минем уңышларны күргәч,
Көнчеләр тагын нишләр?
Эштән соң күпләр эчәр...

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Кайтырбыз җиңеп.

Без кайтырбыз туган якка,
Көтегез дуслар.
Ерак, бик ерак булса да,
Барасы юллар.

Җиңеп фашист калдыкларын,
Кайтырбыз дуслар.
Җир Анабыз каршы алыр,
Сайрарлар кошлар.

Без кайтырбыз туган йортка,
Геройлар булып.
Әниләр каршы алырлар,
Шатлыктан елап.

Көтегез Сез бары безне,
Сөекле ярлар.
Мәхәббәттән тиз савыгыр,
Безнең яралар.

Без кайтырбыз сагынып Сезне,
Булырбыз бергә.
Күкләребез тыныч булыр,
Гомер, гомергә!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Исемеңне яздым.

Кәгазь кисәгенә,
Исемеңне яздым.
Онытырмын диеп,
Никтер уйладым.
Күз алдыннан китми,
Синең карашың.
Йөрәгем түрендә,
Минем барасың.
Исемеңне әйтеп,
Таңнан уянам.
Синең булуыңа,
Бик тә куанам!

## Тукай булса.

Тукай булса арабызда бүген,
Әйтер иде кирәк сүзләрне:
Уяныгыз, әй, татарлар диеп,
Ачар иде йомык күзләрне.

Бөек Тукай булса арабызда,
Җиңел булыр иде суларга.
Тулы күкрәк белән сулыш алып,
Теләр идем яшәп алырга.

Вируска да аның әйтер сүзе,
Булыр иде, камил иманым.
Кагылма син, милләтемә диеп,
Бирер иде аңа кирәген.

## Үземнеке.

Барысы да үземнеке,
Ничек туган шулай бар.
Барысы да миңа охшый,
Җәен-яңгыр, кышын-кар.

Барысы да үземнеке,
Туган ягым, туганнар.
Күршеләрем, авылдашлар,
Барыда тырыш, уңганнар.

Барысы да үземнеке,
Раббым ничек яраткан.
Иң матур кыз үземнеке,
Ул минем туган яктан.

Барысы да үземнеке,
Эштә эшләп табылган.
Байлык, ялган колы түгел,
Кеше булып калынган.

Барысы да үземнеке,
Тирләп, эшләп табылган.
Гадел, тырыш дигән исем,
Тирә юньгә таралган.

Барысы да үземнеке,
Көчләр белән табылган.
Кара алтын таба-таба,
Бик күп көчләр куелган.

Барысы да үземнеке,
Шуңа күрә кадерле.
Рәхмәтле булырмын сиңа,
Белә алсаң кадерне!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Максат.

Тарихка кереп калырга,
Мин бик тырыштым.
Кара алтын белән дә мин,
Бик тиз таныштым.

Утыз ел тырышып таптым,
Кара алтынны.
Хезмәтемнең нәтиҗәсе,
Орден, медальме?

Әлегә юк, бик көттерә,
Олы дәрәҗә.
Этәргеч юк, шуңа күрә,
Этеп җибәрә.

Көтәм әле, бары да безгә,
Авыр бирелә.
Эшемне дәвам итәрмен,
Җиткереп җиренә.

Максатларга ирешергә,
Раббым насыйп ит.
Югары үрләрне алып,
Яшәү рәхәт бит!

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Бәяләү.

Шигырьләрне язып бетердем дә,
Бәяләргә булдым аларны.
Танышыма бирдем, укы диеп,
Тиз чыгарды дустым карарны.

Шәп булган бу, тагын бармы диеп,
Дәвам итте, укып шигырьне.
Әлбәттә бар, өстәл тулы дидем,
Күрсәт диде, бүлеп сүземне.

Өстәл тулган кәгазь, шигырь белән,
Киштәләрдә тулган алардан.
Тик бер сорау, зинһар әйтче диде,
Аласың син илһам кайлардан?

Тормыш дидем, үзе илһам бирә,
Күрә белү бары бик мөһим.
Күңел күзең күрә белмәсә тик,
“Сукыр” булуың да бик мөмкин.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Әнкәм булса яннарымда.

Әнкәм булса минем янда,
Карар идем аның күзенә.
Киңәшләрен аның тыңлар идем,
Колак салып һәрбер сүзенә.

Әнкәм әгәр булса арабызда,
Икмәк булыр иде өстәлдә.
Мичтән яңа чыккан, тәмле икмәк,
Күпме көч ул бирде үскәндә.

Бүген Әнкәм булса минем белән,
Кунак булыр иде өемдә.
Урыны да булыр иде түрдән,
Җылы, якты өйнең түрендә.

Бергә булмасак та әнкәм белән,
Йөрәгемдә аны мин йөртәм.
Искә алам, сагынып искә алам,
Бәлки кайтыр диеп бик көтәм!

Әнкәм әгәр булса минем янда,
Карар идем аның йөзенә.
Рәхмәтләрне кат-кат әйтер идем,
Карап җылы, яшьле күзенә!

## Илһам.

Илһам белән Илһамия,
Очрашсалар күңелдә.
Яхшы уйлар кайнап ала,
Күңелемнең түрендә.

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Сау бул.

Сау бул беренче мәхәббәт,
Сау бул беренче сөю.
Сине саклап кала алмадык,
Калды җанда тик көю.

Көйдереп, җанны өздереп,
Өшетеп ул югалды.
Нахак әйткән синең сүзләр,
Күңел түрендә калды.

Йөрәкләрдә авыр яра,
Сызлады көнен, төнен,
Кызганмады хәтта никтер,
Яшьлекнең бик яшь тәнен.

Бик озак төзәлде яра,
Сызлады, аптыратты.
Бары чын мәхәббәт килгәч,
Иртән матур таң атты!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Алга милләтем!

Үз милләте белән горурланып,
Яшәүчеләр җирдә күп микән?
Бу сораулар мине көндә борчый,
Җавап табулары биктә авыр икән.

Очраштырды тормыш бервакыт,
Бер язучы белән, бер эштә.
Шигырьләрне минем кире какты,
Ләкин йөрәк әйтте-бирешмә!

Шигырләреңне синең укыгач та,
Искә төште диде СССР.
Барабаннар кагып баралар күк,
Пафос белән алар язылган,
Кемнәрдән соң үрнәк алынган?

Туфан абый миңа якын дидем,
Якын миңа Роберт Миңнуллин.
Ә ул әйтте укы бүтәннәрне,
Дөрес алмагансың үрнәк син.

Килешмәдем бу язучы белән,
Бүтәннәрнең фикерен белдем.
Үз милләтен алга алып барган,
Шагырьләрнең барын мин күрдем!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Эшлибез эшләрдә без.

Дүшәмбедән, җомгага,
Барабыз бары алга.
Аннары ике көнгә,
Китәбез теләп ялга.

Тырышып эшлибез без,
Бик тиз үтә көнебез.
Атна үтеп киткәнен,
Беребездә сизмибез.

Менә ял килеп җитте,
Атна үзәккә үтте.
Нервыларны төзәтергә,
Вакытлар килеп җитте.

Шимбә иртәсе рәхәт,
Я, Раббым сиңа рәхмәт!
Бер кешедә борчымый,
Ял бирә безгә сихәт.

Үтеп китте ике көн,
Булды төшме, әллә өн?
Ял итәргә язмады,
Бер хәлем дә калмады.

Яңа атна башлана,
Эшләр миңа “ташлана”.
Бармый алар башкага,
Түзсен бары баш кына!

## Язучының мәхәббәте.

Язучының мәхәббәте,
Аның шигырьләрендә.
Республика горурлыгы,
Татар шагыйрьләрендә.

Шигырьләрдә Туган якның,
Матурлыгы чагыла.
Шушы матурлыкны күреп,
Кунаклар күп агыла.

Татар җыры, татар моңы,
Күңелгә үтеп керә.
Тукай шигырен укысаң,
Яшәргә ул көч бирә.

Татар халкы, тырыш халык,
Иң беренче эшләрдә.
Иген игә, мал асырый,
Белә ниләр эшләргә.

Булдырабыз диеп әйтергә,
Татарларның бар хакы.
Нинди эшкә тотынса да,
Яхшы була азагы.

## Үрнәк булып.

Бүтән халыкларга үрнәк булып,
Яшәү кирәк, минем милләтем.
Татарлар ул тырыш, бөек халык,
Саклап калыйк без татар телен.

Бердәмлектә бары безнең көчләр,
Иман булсын безнең күңелдә.
Дин кушканча яшәү насыйп булсын,
Аллаһ булсын йөрәк түрендә.

Мин татар диеп горурланып,
Яшәргә безгә язсын.
Татар җанлы кешеләргә,
Бик күп рәхмәтләр яусын!

## Көләч йөзле Әнием.

Әниемнең җылы куллары,
Искә төшкән саен җылыта.
Арабызда түгеллеге искә төшкәч,
Күз яшьләре белән елата.

Әниемнең көләч йөзләре,
Янып торган матур күзләре.
Күз алдыннан китми карашы,
Бигрәк тәмле иде һәр ашы.

Әниемнең әйткән сүзләре,
Тормыш авыр улым, түз яме.
Үз көчеңә бары син ышан,
Җәй көненә әзерлән кышын.

Җәйләр җиткәч, кышны онытма,
Эш юк диеп, йоклап син ятма.
Иртә торсаң эшең тиз бетәр,
Авырлыксыз кышлар тиз үтәр.

## Төшкә керде.

Төшкә керде көз аеның,
Яңгырлы, салкын көне.
Йөрим икән мин урамда,
Сагынып, эзләп сине.

Сөйгән чакта көз көне дә,
Матур язлар шикелле.
Күзгә күренми болытлар,
Кәеф яхшы, билгеле.

Очып, йөгереп йөрисең,
Өлгерәсең күп эшкә.
Бәхет ерактан күренә,
Тәэсир итә йөрешкә.

Уянып киттем, таңнар аткан,
Урамнарда кыш көне.
Бәхет телим, сезгә дуслар,
Тулы санлы ел буе!

## Хәтерләтте Яңа Елны.

Сары, тәмле мандаринны,
Алып кайттым өемә.
Өстәл артына утырдым,
Матур, татар көенә.

Өйнең эчен басып алды,
Исе мандариннарның.
Хәтерләтте Яна Елны,
Утыз беренең төнен.

Искә төште бала чаклар,
Җигелгән парлы атлар.
Кыш Бабайга диеп язылган,
Котлаулы безнең хатлар.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Кичәге түгел.

Мин инде бүген,
Кичәге түгел.
Сине сагынып,
Еламый күңел.

Онытып барам,
Авыр булса да.
Йөрәкләремдә,
Яра калса да.

Сөю эзләре,
Ерак калдылар.
Кара чәчләрне,
Агартты алар.

Очрату сине,
Насыйп булгандыр.
Йөрәктә сиңа,
Урын калгандыр.

Син диеп тибә,
Бүген йөрәгем.
Рәхмәтләр яусын,
Сиңа сөйгәнем!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Догалар кыла микән?

Туганнарын җирләгәннәр,
Догалар укый микән?
Өче, җидесе, кырыгы,
Барлыгын белә микән?

Илле икесе көнендә,
Сөякләр таркаладыр.
Фәни дөньядан киткәннәр,
Догалар көтәләрдер.

Белмибез гореф-гадәтләр,
Нидән бездә гыйбәрәт.
Бик күпләр хәтта белмиләр,
Нәрсә икән тәһарәт.

Өйрәнергә иде барысын,
Юктыр өйрәтүчеләр.
Бу безгә кагылмас димә,
Җирдә көн күрүчеләр.

Яшибез ничек телибез,
Белмибез татар телен.
Белмибез гореф-гадәтләр,
Һәм бурычлар барлыгын.
Тагын күп нәрсә тагын.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Күршенеке күркә.

Чит бакчадагы чәчәкләр,
Матур булып күренә.
Күршенең хатыны матур,
Повезло же күршегә.

Күрше тавыгы да күркә,
Хатыны бигрәк иркә.
Күршенең хәтта бакчасында,
Яшелчә үсә иртә.

Иң беренче кояш чыга,
Никтер күршеләр өчен.
Кояш бата, айда калка,
Аларга беренче ни өчен?

Лачыным диеп дәшә иренә,
Безнең күрше хатыны.
Чәчкәм диеп җавап бирә,
Ире кочаклап аны.

Шулай дуслар, күрмибез никтер,
Үзебезнең бәхетне.
Күршеләр безнең кебек, тик,
Була белә бәхетле.

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Кан бирүче.

Минем каным ярдәм итсә,
Бер кешегә, яшәр өчен.
Шатлык булыр, хәлем бетмәс,
Артыр бары минем көчем.

Минем каным ярдәм итәр,
Авыр хәлдә булганнарга.
Үрнәк булыр куркакларга,
Читтән карап торганнарга.

Минем каным ярдәм итсен,
Хаста кеше тиз терелсен.
Белмәсә дә мине үзе,
Мин якыны, белеп торсын.

Кан бирүче мәңге яшәр,
Табиб аңа Сез диеп дәшәр.
Ярдәм итү чит кешегә,
Бездән соң да ышанам, яшәр!

## Кызыл миләш.

Кызыл миләш, кызыл миләш,
Син булдың миңа сердәш.
Сөйгәнемне ничек табыйм,
Бирче, бир зинһар киңәш.

Миләш тәлгәшләре кебек,
Кызарам кызлар күргәч.
Ул миннән читләргә китте,
Миңа вәгъдәләр биргәч.

Көтәм әле көзгә хәтле,
Көзен пешә миләшләр.
Үземнең бердән-беремне,
Көтәм, дуслар кардәшләр.

Сезгә әгәр очраса ул,
Сөюемне әйтегез.
Минем булачак бәхеткә,
Сез дә өлеш кертегез!

## Бер рәттән.

Ирләр белән рәттән торып,
Кызлар тәмәке тарта.
Икенчесе сыра белән,
Бала арбасы тарта.

Балалары карап үсә,
Әниләренең шөгелен.
Күптә үтмәс алар башлар,
Күрергә үзләренең көнен.

Агуланып алар үсә,
Бик кечкенә вакыттан.
Сыраны да сатып ала,
Бик тә зур ул савыттан.

Нинди көн бүләк итәсез,
Балаларга сез бүген?
Күрмичә үсәләр алар,
Матур дөньяның күген.

# Йөзем якты.

Йөзем якты, яхшы кешеләргә,
Ишек ачык, үзем ишеләргә.
Урын түрдә гади кешеләргә,
Омтылам мин дөрес яшәргә.

Үрнәк алам, үрләр яулаганнан,
Теләп калам, түз диеп егылганга.
Тора алмаса, тор диеп ярдәм итәм,
Кул сузганга хәер биреп китәм.

Елмаямын, миңа елмайганга,
Сөенәм мин җылы, язгы майга.
Йөзем якты, матур таңнар атты,
Кошлар сагынып тагын безгә кайтты.

Йөзем якты, яхшы кешеләргә,
Ишек ачык, дуслар, туганнарга.
Ризык пешкән, өстәлләрем иркен,
Шундый матур дуслар, бүгенге көн!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Иссез.

Акчаның исе юк диләр,
Ничек инде булмасын.
Балаларга аңлатыйк,
Бездән серләр калмасын.

Эшләп табылган акчадан,
Тир исе бәлки килер.
Аллаһ аның иясенә,
Саулык һәм муллык бирер.

Бик җиңел килгән акчадан,
Таныш түгел ис килер.
Ул акчаның хуҗасына,
Мәшакатьләр күп килер.

Акчаның исе юк диләр,
Ә мин килешә алмыйм.
Хәрәм булмасын акчалар,
Мин шуны яхшы аңлыйм.

## Яшьлек.

Әй син яшьлек,
Нинди матур мизгел...
Шатлык йөздән китми иде гел.
Һава торышына карамастан,
Кошлар кебек җырлый иде күңел.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Хатлар язмыйбыз хәзер.

Хатлар без хәзер язмыйбыз,
Китаплар укымыйбыз.
Барыбыз да телефоннан,
Күзне ала алмыйбыз.

Ашыйсы килсә дә хәзер,
Шалтыратабыз гына.
Кэшбэкларга бик кызыгып,
Күп акчалар тотыла.

Өчне алсаң дүртенчесен,
Бушка бирәбез диләр.
Ышанырга тик ашыкма,
Булма син, булма юләр.

Чын акчалар онытыла,
Карта белән түлибез.
Кесәләрдә бер тиен юк,
Ләкин ачтан үлмибез.

Иляәштек рәхәткә без,
Дөнья кая барадыр.
Күптә үтмәс роботларда,
Дөнья буйлап таралыр.

Алыштырып кешеләрне,
Алар эшләр авыр эш.
Кешеләр хәтта йөз яшьтә дә,
Сакланып калып бик яшь.

## Үз кояшың.

Үзеңнең кояшың,
Булсын ул бу җирдә.
Кочаклап бер алгач,
Ныклап тот, җибәрмә!

Үзеңнең ризыгың,
Булсын ул өстәлдә.
Шөкерне әйтсәң син,
Күп нәрсә өстәлә.

Шөкер диеп йөргәнгә,
Шөкер диеп күргәнгә.
Изге булса уең,
Төшмәссең түбәнгә.

Үзеңнең тормышың,
Үзеңнең язмышың.
Язмыштан узмыш юк,
Диеп син ялгыштың.

Үзеңнең нигезең,
Булсын ул дөньяда.
Алга бары атла,
Бул һәрвакыт син алда!

## Кемдә кемнең эше бар.

Кемдә кемнең эше бар,
Хәзер урамнарда тар.
Май аена карамастан,
Бездә ява ап-ак кар.

Кемдә кемнең эше бар,
Бармы синең юкмы пар.
Берәүләрнең берәүдә юк,
Кайберләрнең ике яр.

Кемдә кемнең эше бар,
Ин мөһиме акча бар.
Акчаң булса, иркен урам,
Һәр көн саен яңа яр.

Кемдә кемнең эше бар,
Ишекләрдә йозаклар.
Күршеләр күршегә керми,
Бер-берсеннән туйганнар,
Шуңа бикләп куйганнар!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Ярты.

Һәр нәрсәнең була үз яртысы,
Ак төснең дә була карасы.
Бала тугач анның өчен күпме,
Йөрәккәйнең сызлый ярасы.

Төннәрдә дә якты көннәр була,
Ә көннәрен була караңгы.
Якты була сөю булса янда,
Сөю китсә киләдер кайгы.

Көн булмаса төндә булмас иде,
Булмас иде күктә йолдызлар.
Төннәр үтми таңнар атмас иде,
Кояш чыкмас иде иртәдән.

Мин булмасам, синдә булмас идең,
Китек булыр иде күңелең.
Син булып та, әгәр мин булмасам,
Бик тар булыр иде киң илең.

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Төрле яшьтә.

Утыз яшьтә әгәр берәр кеше,
Яман сүзләр белән эндәшсә.
Бирер идем аның кирәген мин,
Йодрык белән инде, әлбәттә.

Кырык яшьтә әгәр берәр кеше,
Кырын карап миңа эндәшсә.
Этләр өрә, бүре йөреп тора,
Әйтә идем эчтән, эндәшмә.

Илле яшьтә әгәр берәр кеше,
Гайбәт чәчсә безнең тарафка.
Каршысына аның килеп баскач,
Тына иде, карап карашка.

Алтмыш яшьтә кеше ниләр сөйли,
Кирәк түгел инде белергә.
Намазларны биш кат укып, шөкер,
Җомгаларга язсын йөрергә.

Һәр мизгелнең кызган чагы була,
Сугып кал син кызу чагында.
Дошманнарың синнән куркып торсын,
Дуслар булсын синең ягыңда!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Кыюлык өчен.

Сәхнәгә чыгып басуга,
Югалды фикер.
Дустыма әйттем: -“Ник алай?”,
Ул әйтте: -“Төкер!”.

Ә син,- диде,
Сал 100 грамм, кыюлык өчен.
Сизәрсең син шул вакытта,
Хәмернең көчен!

Нервыларың тынычланыр,
Куркуың качар.
Аек яшәү бу дөньяда,
Беләм, бик начар.

Кара күзлегеңне киеп,
Чык син сәхнәгә.
Чын артистлардан үрнәк ал,
Фонограмма нигә?

Алдан яздыр җырларыңны,
Яхшы бер дискка.
Авызыңны ачып тик тор,
Борчылма юкка.

Мин әлбәттә килешмәдем,
Дускаем белән.
Үз-үземә бурыч куйдым,
Сәхнәгә өйрән.

Күзгә каршына килеп бас,
Җырыңны көйләп җибәр.
Сәхнә өчен син тугансың,
Кара нинди син, чибәр!

Аек фикер, аек акыл,
Булса бик яхшы.
Хәмер белән дуслашмасаң,
Көннәрең якты!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Кая бара дөньясы.

Кулында сыра шешәсе,
Авызында тәмәке.
Килешми сиңа, белеп тор,
Яман гадәт, әшәке.

Яшьлегеңнең матурлыгын,
Югалтасың анламый.
Табибларда бик тә теләп,
Ярдәм итә ала алмый.

Үзең сатып алган чирне,
Теләрсең дәваларга.
Ләкин вакыт үткән булыр,
Әле соң түгел, аңла!

Табигатьнең һәм күкләрнең,
Гүзәллегенә соклан.
Изгелек кыл, саваплар җый,
Матур җыр тыңлап, моңлан!

Сөюләреңне син аңлат,
Чибәр, уңган бер затка.
Гаилә корып син җибәр,
Бирмә син аны ятка.

Без бу җирдә кунак кына,
Өч көнлек дөнья диләр.
Һәр минутның кадерен бел,
Тыңла син мине, юләр!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Халыкныкы мин.

Мин халыктан ерак түгел,
Дәрәҗәм юк дигән- “данлыклы”.
Халыкныкы, бары халыкныкы,
Бу исемнән ни бар кыйммәтле?

Утыз ел мин табам кара алтын,
Юк әлбәттә Майбах, Мерседес.
Этәргеч юк, шуңа күрә әле,
Эшлимен мин дуслар медальсез.

Бирешмимен, тыныч кына эшлим,
Кара алтын ага торбадан.
Иртән иртүк торып эшкә китәм,
Күп кешеләр әле тормаган.

Халыкныкы булып калам әле,
Бу исем бик миңа килешә.
Белеп торсын эшемдә түрәләр,
Нефть таба егет, тырыша!

Мин халыктан ерак түгел,
Дәрәҗәм юк дигән- “данлыклы”.
Халыкныкы, бары халыкныкы,
Бу исемнән ни бар кыйммәтле?
Бу исем бик миңа кыйммәтле!
Шуңа күрә сезгә рәхмәтле!

## Гафу итче авылым.

Авылдан килдем шәһәргә,
Матур итеп яшәргә.
Авыр булса да түзәм мин,
Уем юк бирешергә.

Авылдан килдем шәһәргә,
Эш күп монда яшьләргә.
Ләкин кичләр җиткәч никтер,
Күзләр минем яшьләнә.

Авылымны мин сагынам,
Сагынам авыл кызын.
Су буенда йөзеп йөргән,
Сары бәбкәле казын.

Битәрлимен һәр кич шулай,
Үземне тирги-тирги.
Ни җитмәде авылымда?
Бу сорау тынгы бирми.

Имеш шәһәрдә яшәргә,
Җиңел яшьләргә биктә.
Китәр идем моннан качып,
Горурлык әйтә, китмә.

Тамыр җәеп син җибәрдең,
Син шәһәрнең өлеше.
Улың үсә, агач утыртылган,
Үз урының сиңа килешә/

Шулай дуслар, авыл төшкә керә,
Еллар үткән саен ешырак.
Терсәк якын, ләкин тешләп булмый,
Яшьлектән дә үткән ел ерак.

Йөрәгем, күңелем белән,
Мин авылныкы һаман.
Авылым гафу ит мине,
Дуслар, шигырем тәмам!

## Сөяксез тел.

Тел бит ул сөяксез дуслар,
Сөйли дә, сөйли.
Ни күрәсен ул үзенең,
Ул әле белми.

Болай икән, шулай булган,
Син ишеттеңме?
Күрше әнә ни эшләп йөри,
Син аны күрдеңме?

Гайбәт сата көннәр буе,
Безнең телебез.
Белмибез һәм ишетмибез,
Нинди соң үзебез?

Эше булган кешеләрнең,
Юк бер вакыты.
Кеше сөйләп алар йөрми,
Эшләре каты.

Әйдә дуслар, тату яшик,
Көнләшми генә.
Ничек яшәсәң дә үтә,
Гомер бер генә!

## Ява яңгыр.

Яңгыр ява, җәйге яңгыр ява,
Кайтып киләм юлның кырыннан.
Күзем төште шулчак чибәр кызга,
Ким түгел ул патша кызыннан.

Бер күрүдә ана гашыйк булдым,
Сизәм эшләр харап, бик харап.
Танышырга теләп башны идем,
Ул елмайды миңа бер карап.

Җәйге яңгыр, рәхмәт сиңа яңгыр,
Юлларымны минем чылаттың.
Гомер буе таба алмый йөргән,
Гүзәл затны таптым, яраттым.

Мин бәхетле күрә алган өчен,
Шушы матур кызның йөзләрен.
Күзләренә аның туры карап,
Яратам диеп әйтә алган өчен!

## Табигать.

Табигать гафу итәрме,
Безне кешеләр.
Зарарланган табигать белән,
Балалар ни эшләр?
Машиналар тәүлек буе,
Чабалар юлдан.
Заводларның төтеннәре,
Еракка сузылган.
Көн-төн алар бүген эшли,
Товар чыгара.
Агуланган шакшы сулар,
Елгага ага.
Елгалардан диңгезләргә,
Кушыла сулар.
Кошлар, балыклар, җәнлекләр,
Калырмы дуслар?
Кызыл китапка керсәләр,
Ниләр эшләрбез?
Эчәрлек сулар бетсәләр,
Кое тишәрбез?
Якларга кирәк бүгеннән,
Күкне, суларны.
Урманнарны, җәнлекләрне,
Болын, кырларны!

## Сине күреп.

Сине күрдем бүген,
Тагын төштә.
Рамашкалы матур күлмәктән.
Әйтерсең лә,
Шундый матур кызны,
Мин беркайчан да,
Әле күрмәгән.
Кара күзле,
Чәче дулкын, дулкын,
Карашлары миңа бик якын.
Адымнары, йөзгән ак кош кебек,
Йөрәгемдә капты көчле ялкын.

## Халыкныкы мин үзем.

Мин халыктан чыккан нефтьче,
Шуңа да мин бик тә, бик көчле.
Авырлыклар бер дә куркытмый,
Ни булсада кичен таң атмый.

Һәр нәрсәнең була үз җае,
Гомерләрнең яшел үз җәе.
Кышлар җиткәч ап-ак кар ява,
Язлар җиткәч эреп югала.

Көзләр җиткәч уңыш җыела,
Тормыш бара үзенең җаена.
Сизелмичә үтә гомерләр,
Искә алгач елар, я көләр.
Әйтер тагын: “Нинди син юләр?”.

Юләр түгел, бары хыялый,
Мин яшь диеп үзен алдалый.
Ярамыйга бердә карамый,
Бара һаман, бара туктамый,
Туктарга да никтер ярамый.

## Алдау/Ялган.

Бик күп сүзләрдә,
Алдау һәм ялган.
Кемнәрдән соң ул,
Үчләрен алган?

Күзләрендә күп чак,
Ялган карашлар.
Күзләрендә күп чак,
Ни эшләптер яшьләр.

Дөреслек ул юктыр,
Дөньяда бүген.
Ялган хисләр баскан,
Дөньяның күген.

Ясалма керфекләр,
Ясалма кашлар.
Ясалма иреннәр,
һәм буш кешеләр.

Чынбарлыкка җитми,
Ни эшләсәң дә.
Дөреслек өчен кызганыч,
Түгел үлсәң дә!

## Кичке авыл.

Кичке авыл,
Ишетелә
Ерак түгел
Уйный бер баян.
Авыл кызларының
Йөрәкләре
Бик еш тибә
Кем ул шулай
Матур уйный?
Килеп чыкты
Безгә ул кайдан?
Кичке авыл,
Төн дә килеп җиткән
Ләкин йоклар вакыт
Түгелдер
Матур итеп берәү
Гармун уйный
Бик күпләрнең
Качты йокылар.
Кем ул шулай
Матур уйный?
Килеп чыкты
Безгә ул кайдан?

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Нидер җитми.

Өстәл өсте тулы ризык белән,
Өебездә җылы һәм якты.
Нидер җитми ләкин күңелемә,
Бервакыттан күздән яшь акты.

Әти-Әни җитми минем янда,
Никтер күңел елый сагынып.
Кунакларга чакырырга иде,
Өйләремдә кунакка алып.

Күрсәтергә иде зур йортымны,
Буйга үсеп җиткән улымны.
Өйнең түрләреннән урын биреп,
Күрсәтергә иде хөрмәтне.

Рэхмәтемне әйтеп сыйлар идем,
Кунак итәр идем бик озак.
Ләкин чакыруны алар ишетмәсләр,
Әти-Әни инде бик ерак.

Догаларны укып, искә алам,
Әти-Әниемне көн саен.
Исән чакта тырышыгыз хөрмәтләргә,
Табыгыз сез күрешү җаен!

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Бәлеш пешә.

Кышкы салкын кичләрдә,
Бәлеш пешә мичләрдә.
Сөтләп без чәй эчәбез,
Матур, якты кичебез.

Күктә йолдызлар яна,
Әнә ай балкып тора.
Ерак түгел галәмдә,
Бармы икән әдәмнәр?

Бардыр әлбәттә, бардыр,
Хыялларыңны калдыр.
Күктә күренсә йортлар,
Анда ниндидер алар?

Күктә йолдызлар яна,
Болытлар кайда ага?
Алар бергә җыелгач,
Ап-ак карлар да ява.

## Кыска кеше гомере.

Кеше гомере кыска,
Тормыш тарта гел аска.
Төз торыр өчен кирәк,
Охшарга яхшы атка.

Тормыш йөгәнен киеп,
Мәшакатьләрен өеп.
Барырга бары алга,
Тырышырга, атларга.

Ял итим диеп туктасаң,
Арып әгәр егылсаң.
Таптап китәрләр күпләр,
Дөбердәр шулчак күкләр.

Кыска кеше гомере,
Һәр кешенең үз эзе.
Яхшы гамәлләр кылса,
Якты кешенең йөзе.

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Яратам.

Яратам авыл кызларын,
Саф алар һәм сөйкемле.
Тыйнак, матур һәм уңганнар,
Гади үзем шикелле.

Эчкерсез, чиста күңелле,
Акыллы безнең кызлар.
Алар өчен бервакытта,
Кызармас безнең йөзләр.

## Гузәл Әни.

Әнием иң гүзәл иде,
Уңганнарның, уңганы.
Тырыш иде бар эшкә ул,
Булганнарның булганы.

Сигез бала ул үстерде,
Бик авыр заманнарда.
Утын кисеп мичкә якты,
Кышкы ул салкыннарда.

Чәшке туныда юк иде,
Юк иде алтыннары.
Мейкап дигән сүзне белми,
Бик матур тырнаклары.

Матур итеп ул киселгән,
Буялмаган лакларга.
Ясалма керфекләр дә юк,
Шуңа була мактарга.

Ә хәзер кашлар “ясалган”,
Мейкап тәүлек буена.
Ясалма керфек, татулар,
Гәүдәсенең буена.

Гүзәлләрнең иң гүзәле,
Тырыш, матур һәм уңган.
Әниемнән без балалар,
Яхшы үрнәкләр алган,
Барыда истә калган.

## Әни догалары.

Исән-сау йөр балам диеп,
Кала иде Әни озатып.
Юллар уңа иде шуңа күрә,
Аллаһ йөртә иде күзәтеп.

Әни догалары алар изге,
Чишмә суы кебек саф алар.
Авырлыклар була калса әгәр,
Даруларсыз дәвалый алар.

Әниемнең гади догалары,
Бүгенгедәй әле исемдә.
Булганына шөкер әйтеп яшим,
Татарстан дигән җиремдә.

Улыма да белгән догам белән,
Ярдәм итә алсам юлында.
Бәхетләре безнең балаларның,
һәрбер ата-ана кулында.

Раббым сакла, зинһар өчен,
Минем газиз баламны.
Үзем янында булмасам,
Көнем була караңгы.

Яхшы кешеләр һәрвакыт,
Булсын аның янында.
Яхшы гамәлләр ул кылсын,
Иман булсын җанында.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Иман.

Мәчетләр дә, чиркәүләр дә бик күп,
Ник күпләрдә юк икән иман?
Җомга көнне барлык мәчетләрдә,
Ишетелә имам әйткән азан.

Ят калмады җирдә ни өчендер,
Бик күп кызлар тарта тәмәке.
Гәүдәләре “тату”ларга баткан,
Ике сүзнең берсе әшәке.

Дөнья куып бик күпләр онытa,
Үзләренең газиз баласын.
Аңламыйлар яшьлек үтеп киткәч,
Йортларында ялгыз каласын.

Кешелеклек, әхлак сыйфатлар,
Кайда калдылар икән?
Хәмер эчеп көн күргәннәр,
Берәр айнырлар микән?

Иблис әллә үз артыннан,
Ияртеп йөри микән?
Тыйганнардан тыелырга,
Вакытлар күптән җиткән!

## Җомга иртәсе.

Коймак исе белән тулган,
Өйдә җомга иртәсе.
Әнкәм мичкә яккан бүген,
Килми эшкә китәсе.

Без торуга ризык пешкән,
Чәй кайнаган өстәлдә.
Йолдызкаем без үссен диеп,
Сөттә биргән өстәмә.

Нинди рәхәт үсмер чаклар,
Әти-Әни янында.
Мәшакатьләр дә юк сыман,
Алар исән чагында.

Тормыш тора ак-карадан,
Китә алар арадан.
Йөрәк елый, сыкрый озак,
Шундый авыр ярадан.

Кадерләрен белеп, зурлап,
Хөрмәтлик Әниләрне.
Хәлләрен гел белеп торыйк,
Онытмыйк Әтиләрне!

## Кызыл Лада.

Чабабыз алга,
Кызыл Ладада.
Кайтып киләбез,
Туган авылга.

Җилләр исәләр,
Лада артыннан.
Шәһәргә кайтыш,
Туган авылдан.

Ике арада,
Йөрибез чабып.
Күңел гел тарта,
Туган авылга.

Авылда яллар,
Бик тиз үтәләр.
Шәһәрдә безне,
Эшләр көтәләр.

Атна үткәнен,
Зарыгып көтәм.
Кызыл Ладада,
Авылга китәм.

## Яхшы иде.

Элек яхшы иде дибез,
Хәзер бүтәнчә никтер.
Никтер риза түгелдер без,
Әйтә белмибез шөкер.

Яхшы иде элек дибез,
Тигез идек күбебез.
Дөнья тыныч, сулар чиста,
Аяз иде күгебез.

Элек яхшы иде дибез,
Шөкер әйтә белмибез.
Очрашканда сәлам әйтеп,
Шатланып ник көлмибез?

Елмаябыз бик сирәк без,
Баскан башны мәшакать.
Начар булса да бирешмә,
Барысы диген әйбәт!

Шөкер диген, Аллам рәхмәт,
Булганына сөенәм.
Элек яхшы булганына да,
Раббыма башны иям!

## Нефтьчеләр урамы.

Нефтьчеләр урамының,
Бигрәк төзек юллары.
Ни өчен диеп сорарсыз,
Тырыш татар уллары.

Кара алтын алар таба,
Җирдәге тишемнәрдән.
Аларның көче юлларны,
Төзекләгәндә кергән.

Кара алтын табу серен,
Бары тик алар белә.
Аларның ярдәме белән,
Шәһәр тиз төзекләнә.

Татар нефтенең шифасы,
Нефтьчеләр кулында.
Нәтиҗәләрен күрәбез,
Шәһәребез юлында.

Рәхмәт сиңа кара алтын,
Республика байлыгы.
Озак еллар дәвам итсен,
Нефтьченең саулыгы!

## Сагындыра туган як.

Тальян гармунның моңнары,
Үтеп керә күңелгә.
Искә төшкәч туган яклар,
Күздән яшьләр күренә.

Сагындыра туган авыл,
Күршеләр һәм урамнар.
Инешләр һәм Чулман буе,
Ерак түгел урманнар.

Сулар һавалары чиста,
Тәмле чишмә сулары.
Уңдырышлы, бигрәк тә бай,
Игенле басулары.

Самоварлы өстәлләрдә,
Мичтә пешкән бәлешләр.
Өстәл артында туганнар,
Иң якын авылдашлар.

## Кырым күпере.

Төзи белмәгән кешеләр,
Җимерергә ярата.
Кырым күпере ни өчен,
Хәрабә булып ята?

Хыяллары чынга ашты,
Шартлаттылар күперне.
Бик күптән алар куркытты,
Куркырлар диеп безне.

Күпердән үчне алалар,
Акыллары булмагач.
Дөньяда бүген яшәүләр,
Бигрәкләрдә куркыныч.

Җавап бирәсе булачак,
Аларга бу эш өчен.
Төзегәндә бу күперне,
Күп кеше куйды көчен.

Безгә дә бәлки кирәктер,
Алар кебек булырга.
Ләкин беләм, кирәк безгә,
Кеше булып калырга!

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Кешелеклелек.

Кешелеклелек сүзендә,
Тирән мәгънә ята.
Бу сүзне кайбер кешеләр,
Бүген никтер оныта.

Куалар алар дөньяны,
Бик матур яшәр өчен.
Кеше башыннан йөриләр,
Уйлап бары үз өчен.

Байлыкка бары табынып,
Үтәр әлбәттә яшьлек.
Искә төшәр яшьлек үткәч,
Килер күзләргә яшьләр.

Кешелеклелек бервакыт,
Кайтыр тагын кешегә.
Иман, вөждан сүзләрендә,
Язса иде ишетергә.

Кешелеклелек сүзендә,
Тирә мәгънә ята.
Бары мөлкәт җыю дуслар,
Белегез олы хата!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Кайтып киләм.

Кайтып киләм Әлмәт каласыннан,
Юл кырында безнең тишемнәр.
Кырлар бушап калган бик күп җирдә,
Уҗымнар да инде тишелгән.

Август аеның да утыз бере,
Җәй сизелми үтте быел да.
Уңда, сулда, бөтен җирдә байлык,
Татарстан дигән җиремдә.

Куанып мин шулай кайтып киләм,
Кара алтын-халык байлыгы.
Республикабызны ныгыта ул,
Бюджетның да шактый өлеше.

Кара алтын табам мин тырышып,
Эшемне мин биктә яратам.
Булсын диеп, армый-талмый эшлим,
Җирдә яхшылык мин таратам,
Туган ягым сине яратам!

## Мәктәптә соңгы кыңгырау.

Соңгы кыңгырау олы юлга,
Безгә ишекләр ача.
Рәхмәт әйтеп мәктәпләргә,
Чыгып китәбез юлга.

Кемдер инженер булачак,
Кемдер танылган табиб.
Кайсы берсе эшли башлар,
Яраткан эшен табып.

Кайда гына укысак та,
Калыр йөрәктә мәктәп.
Укудан сон туган якта,
Тырыш эшләрбез, әйбәт.

Ә хәзергә уңышлар тик,
Бер-беребезгә телибез.
Соңгы кыңгырау көнендә,
Бик тә бик бәхетле без!

## Дөрес яшә.

Ялагайланып күп чакта,
Тырышалар ярарга.
Дөрес әйтергә куркалар,
Куркалар хәтта карарга.

Дөресен әйтер өчен кирәк,
Күп чакта шул батырлык.
Алдар өчен җитә бары,
Булу биктә, бик куркак.

Үз өстеңә җаваплылык,
Алулары бик кыен.
Дөресен әйтсәң охшамый,
Карыйлар күбесе кырын.

Янәсе син, биктә катгый,
Уйламый хәл итәсең.
Озак эшли син алмассың,
Тиздән бездән китәрсең.

Эшем өчен җавап бирәм,
Бары мин үзем генә.
Бу эштә эшләп калырга,
Кирәк түземлек кенә.

Эт өрә, бүре йөри диеп,
Әйткән сүзләр бик дөрес.
Куркыныч эшкә өйрәтәм,
Күпләргә бирәм дәрес!

## Татар исемен акла.

Яше, карты сүгенәләр,
Әйтеп начар сүзләрне.
Әй, җәмәгать беткән мени,
Татарның яхшы сүзе?

Туган телен кадерләгән,
Халык кадерле булыр.
Бу мәкальне истә гел тот,
Башыңда мәңге калдыр!

Бөек татар телебезне,
Кадерләп һәрчак сакла.
Бөек Тукайны укып чык,
Татар исемен акла!

## Чагыштырып кара.

Зарлансагыз мин бәхетсез диеп,
Барыгыз сез хастаханәгә.
Берәү ята аяклары йөрми,
Икенчесе күрми интегә.

Зарлансагыз мин бәхетсез диеп,
Барыгыз сез картлар йортына.
Балалары булып алар ятим,
Сатылганнар алар “яртыга”.

Мин бәхетсез диеп зарлансагыз,
Эзләмәгез булмас гаепләр.
Күзегезне ачып сез карагыз,
Тирә-якта күпме гарипләр.

Башың исән, аякларың йөри,
Йөрәк тибә, тагын ни кирәк?
Булганына шөкер диеп әйтеп,
Яши бары белү тик кирәк!

## Бересе.

365 битлек китапның,
Бүген беренче көне.
Мине эш бигрәк ярата,
Чакыра көне-төне.

Икенче бите дә эштә,
Үтте икенче гыйнварь.
Мине котлаптыр да бәлки,
Ява йомшак ап-ак кар.

Елны ничек башласаң син,
Шулай ул дәвам итәр.
Бүтәннәр әйдә эшләсен,
Миңа бүгенгә җитәр.

Алмаштырып булмый торган,
Кешеләр ул юк диләр.
Каршы киләм, дөрес түгел,
Эш зинһар мине җибәр.

Өйгә кайтып, Яна Елны,
Үткәреп алыйм әле.
Берәр атна искә алма,
Килештек димәк, яме?

Тынлык басты, җавап та юк,
Уйга калдым мин тагын.
Өчесе дә әллә эшкә?
Ял бир диеп ялварам.

Зинһар Раббым ташламасын,
Бары саулыктан мине.
Сау кешегә нәрсә соң эш?
Кагылган миңа эш “җене”.

Эшлимен мин үз эшемне,
Кичә, бүген, иртәгә.
Медалем юк, бары шуңа,
Күңелем бик тә үртәлә!

## Ни өчен?

Ни өчен якын кешеләр,
Үпкәлиләрдер безгә.
Нахак әйткән сүзләрегез,
Ишетелми үзегезгә.

Горурлык дигән богаулар,
Сезне иттеләр әсир.
Барыда яхшы диеп әйтәсез,
Бирмисез кемгә сез сер?

Гафу итегез диеп бүген,
Әйтәм мин үзем сезгә.
Берәр вакыт бәлки булыр,
Ят сезнең үзегезгә.

Аралашып дус, туганча,
Яшик без тату булып.
Әйтәсе сүзләрне әйтик,
Калмасыннар сер булып.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Кирәк түгел калганы.

Кеше тормышы торадыр,
Төрле-төрле мизгелдән.
Кемдер туа, кемдер үлә,
Үтеп булмый язмыштан.

Язмыштан узмыш юк диләр,
Килешәм, бары дөрес.
Күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый,
Тормыш әйтерсең дәрес.

Өйрәтә ул кемне ничек,
Билгеләр куя хәтта.
Бик яхшыга укыганнар,
Яшиләр бик рәхәттә.

Начар билгеләр алганнар,
Алар артта калганнар.
Эшләргә яратмаганга,
Өстерәлеп барганнар.

Яхшы билге алучылар,
Уртача бездә яши.
Ипотекага һәм кредитка,
Көн күреп, эшләп яши.

Кешенеке яхшы кебек,
Ак һәм кара тамгалы.
Ә безнеке бүген шөкер,
Кирәк түгел калганы.

## Томан.

Елга буенда томан,
Минем күлмәк төсендә.
Күпердә басып торам,
Очрашкан минем исемдә.

Йөри идек таңга кадәр,
Матур елга буенда.
Оныттың син никтер мине,
Чакырмадың туена.

Шәһәр тормышын үз итеп,
Чыктын тизрәк кияүгә.
Ашыктың вәгъдәңне бозып,
Алтын балдак кияргә.

Бик күп еллар үтеп киткәч,
Очраштык бергә тагын.
Бәхетлеме?-диеп сорадым,
Алдадың мине тагын.

Күзләреңдә бәхет нурын,
Күрмәде минем күзләр.
Мәхәббәтне алдаганнар,
Кайда барсын соң, түзәр.

Төннәрен елап үтәдер,
Мендәрең һәрчак юеш.
Гафу ит мине диден син,
Акылсыз идем, бик яшь.

Елга өстендә томан,
Күпердә басып торам.
Искә төште яшь чаклар,
Яңарды тагын ярам.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Түгәрәк диләр.

Җир йөзе диләр түгәрәк,
Бик ышанасы килә.
Ләкин тормышны көткәндә,
Еш еласылар килә.

Тормыш түгәрәк булганда,
Кителә бер кисәге.
Ятим итә, алып китә,
Суга дөнья күсәге.

Айныдым бәладән дигәч,
Хыянәте ачыла.
Шул чакларда күңел, йөрәк,
Күп вакытка ябыла.

Дөнья шундый ак-каралы,
Сугышлар чыгып тора.
Күпме ана балаларын,
Югалтып, аһын җуя.

Җир йөзе түгәрәк диләр,
Булсын иде шакмаклы.
Бәлки булыр иде шунда,
Ныгытырга почмакны.

Кителмәс иде ныгыткач,
Җир йөзенең бер кыры.
Сугышларга җитәр иде,
Халык көткән ахыры.

## Татар мин.

Татар мин дуслар, татар мин,
Шуңа да горурланам.
Татар телле булганыма,
Тәүлек буе куанам.

Татар мин дуслар, татар мин,
Иң матур минем телем.
Тукай теле булган өчен,
Әйтәм аңа: “Кадерлем”.

Татар улы мин дусларым,
Татарлар эшчән халык.
Эштән алар тәм алалар,
Бүтән юк мондый халык.

Синең белән калам телем,
Татар телем, кадерлем.
Кайларда булсам да сине,
Кадерләп мин йөртермен!

## Шигырьләр бүләк итегез.

Яратыгыз яратканда,
Сезне ярыгыз.
Хыялларга бирелегез,
Җырлар языгыз.
Шигырьләр бүләк итегез,
Сөйгән кызларга.
Кыш көннәре охшап калсын,
Җылы язларга.
Сөю күңелне җылыта,
Безне яшәртә.
Көч һәм ямь бирә ул,
Безгә яшәргә.
Яшь чагындагы мәхәббәт,
Кала йөрәктә.
Яшьлек үткәч, төшкә кереп,
Безне йөдәтә.

Сау бул диеп сез әйтмәгез,
Сөйгән ярларга.
Бик соң булыр бер бәрелгәч,
Текә ярларга.
Яратыгыз яратканда,
Сезне ярыгыз.
Ярый син бар сөеклем диеп,
Уйлап алыгыз.
Ничек кенә булса авыр,
Бергә түзегез.
Яратышып кушылдыгыз,
Бергә үзегез.
Саклагыз үтеп киткәнче,
Сөю, бәхетне.
Килешерләр минем белән,
Кемнәр бәхетле.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Туган ягым.

Туган ягым рәхмәт сиңа,
Көч бирәсең яшәргә.
Раббым язсын синең белән,
Гомер буе яшәргә.

Рәхмәт сина Туган ягым,
Матур Чулман буйлары.
Нарат, каен урманнары,
Уңдырышлы кырлары.

Сиңа рәхмәт Туган ягым,
Таптым синдә үземне.
Бер күрүдә гашыйк булдым,
Ачу белән күземне.

Яшим синдә мин сөенеп,
Мөселман булганыма.
Байлыгым күп булмаса да,
Ис китми калганына.

Саулык булса күп кирәкми,
Шөкер итеп яшәргә.
Синең матурлыкны күреп,
Тәнем, җаным яшәрә!

## Йокысыз төннәр.

Йокысыз төннәр үткәрдең,
Әни без үскән чакта.
Рәхмәт әйтәм сиңа бүген,
Алып сине кочакка.

Балаларыңны үстердең,
Син миһербанлы итеп.
Үрнәк син безгә күрсәттең,
Бәхетле тормыш көтеп.

Көтә идең безне Әни,
Авылда син сагынып.
Кала идең син озатып,
Капка төбенә чыгып.

Күзләреңдә яшь күренә,
Куллар болгаган чакта.
Без китеп тә өлгермәдек,
Син тагын инде сакта.

Тәрәзәдән күз алмыйсың,
Балалар кайтмыймы диеп.
Гомерең шулай үткәндер,
Без, балаларны көтеп.

Таралыштык зур илнең без,
Төрлебез, төрле якка.
Иң бәхетле булган икән,
Әни син янда чакта!

## Кем баш?

Көчле зат булса да ирләр,
Бирешәләр аларга.
Муен кай якка борылса,
Баш мәҗбүр борылырга.

Борыла баш, кая барсын,
Муен аны бора ич.
Теләмәсәң буйсынырга,
Тыныч үтәр димә кич.

Мин баш диеп кайбер ирләр,
Ярата мактанырга.
Үзе сүзен әйтә алмый,
Бары тик шапырына.

Мин әйткәнчә бара диеп,
Уйлыйлар кайбер ирләр.
Елмаялар хатын-кызлар,
Нинди сез диеп, юләр.

Каршылыклар күп очырый,
Бу сорауны чишкәндә.
Хатын-кызга юл бирегез,
Тормыш юлын үткәндә.

Акыл, хәйлә белән тату,
Хатын-кызлар тормышта.
Алардан башка без ирләр,
Көчле дә түгел, башта.

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Татар гармуны.

Татарның тальян гармуны,
Башкортның курайлары.
Күңелгә шатлык өстиләр,
Туган як тургайлары.

Егетләр, кызлар бииләр,
Әпипәнең көенә.
Татар биюләрен күреп,
Милләттәшләр сөенә.

Мәчетләр чиркәү кырында,
Татарлар урыс белән.
Без бергә, бердәм яшибез,
Безнең көч шунда, беләм.

Күңелдә безнең игелек,
Юк бездә начар уйлар.
Һәрвакыт Татарстанда,
Татулык булыр дуслар.

Шөкер итеп без яшибез,
Кушканча ислам дине.
Сабыр без була беләбез,
Елның 365 көне.

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Кайда калды?

Үз кыйбылаң булсын бу дөньяда,
Һәм әлбәттә булсын үз сүзең.
Матурлыкны күрә белә торган,
Булсын икән дуслар, үз күзең.

Чиста күңел һәм дә изге уйлар,
Булсын дуслар безнең арада.
Йөрәкләрдә булсын кайнар ялкын,
Яхшы булсын яхшы барыда.

Сафлык булсын җирдә без яшәгән,
Дуслык булсын күрше-күләмдә.
Искә алыйк, без кеченә чакта,
Уйный идек яшел үләндә.

Кайда калды, сагынып искә алам,
Ак яулыклы, ап-ак әбиләр.
Һәр сүзләре шифа бирә иде,
Дөрес юлда йөртә иделәр.

Догалары саклый иде безне,
Яман сүздән, күзләр тиюдән.
Юллар безнең шуңа уңа иде,
Чыгып киткәч юлга без өйдән.

## Туган көн.

Туган көннең кадерләре,
Елдан ел арта.
Янда калган тугры дуслар,
Мине ярата.
Алар сирәк, ләкин инде,
Дистә ел бергә.
Безнең дуслык беләм, булыр,
Гомер-гомергә.
Сүзсез дә без бер-беребезне,
Бик тиз аңлыйбыз.
Тормыш юлларын үткәндә,
Бергә атлыйбыз.
Бәйрәм булса, бергә дуслар,
Күңел ачабыз.
Бергә булу кадерләрен,
Тоеп калабыз.
Туганнарым, дус ишләрем,
Хөрмәтем сезгә.
Ниләр булса да без бергә,
Булыйк гел бергә.

## Әйтәсе сүзләр.

Минем әйтәсе сүзләрне,
Кошлар сайрап аңлата.
Синең белән бергә чакта,
Таңнар елмаеп ата.

Мин назлыйсы урынына,
Кояш нурлары назлый.
Син булмасаң яннарымда,
Сыкрап йөрәгем сызлый.

Минем яшьләр урынына,
Җылы яңгырлар ява.
Салават күпере чыккач,
Чистарып кала һава.

Җилләр чыгарып чабам мин,
Сөеклем синең янга.
Соңга калырмын диеп куркам,
Яратам сине, аңла!

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Бәхет төшенчәсе.

Бәхет төшенчәсен бу дөньяда,
Аңлый һәрбер кеше үзенчә.
Берәү бәхетле тик байлык белән,
Хан сарае кирәк кимендә.

Икенчегә кирәк бик кыйммәтле,
Чит илләрдән кайткан машина.
Мөмкинлеге бармы, юкмы, ләкин кирәк,
Карап тормый ниләр хакына?

Өченчесе әйтә-мин кемнән ким,
Миңа кирәк яхта, ак төстә.
Ала алсам, ала алсам әгәр,
Бәхетле мин булыр идем бик тә.

Дөнья булгач кирәк барысыда,
Киң атлап яшәр өчен.
Ләкин моның өчен кирәк,
Эшләп, тирләп, биреп көчең.

Әйтә иде әни юрганыңа карап,
Сузарга син өйрән аякны.
Нәпсе артыннан син куа күрмә,
Югалтма син балам маякны.

Тырышып син эшлә, дөрес яшә,
Ярдәм ит син күрше-күләнгә.
Хөрмәт итәр халык, бай булырсың,
Югарыгы омтыл, төшмә түбәнгә!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Кайтырмын.

Кайгырма Әни, көт диеп,
Китте сугышка егет.
Яшьләнде Әни күзләре,
Калды ул башын иеп.

Ана өчен вакыт үтте,
Сәгате айларга тиң.
Көннәр үтми җафалады,
Йокламый атты һәр таң.

Әнисе догалар укып,
Теләде саулык улына.
Сугыш тынсын диеп теләде,
Корьән алып кулына.

Җиңеп кайтырлар егетләр,
Фашистларның калдыгын.
Тыныч күк йөзе, айлы төннәр,
Алыштырыр яу кырын.

## Алып кайткан диләр өенә.

Булганына риза булмыйча,
Эзләп киттең яхшы тормышны.
Әйтче инде, әйтче миңа хәзер,
Таптыңмы соң андый тормышны?

Без булмаган җирдә барыда яхшы,
Кояш нуры тәүлек буена.
Берәү хәтта күктә янган йолдызныда,
Алып кайткан диләр өенә.

Матур сүзләр әле аңлатмыйлар,
Бик бәхетле җирдә булуны.
Бәхет өчен кирәк бик тырышып,
Һәр көн саен хезмәт куюы.

## Чөнки гашыйк.

Яңгыр ява, мин бәхетле,
Чөнки мин сиңа гашыйк.
Исемдә яныңа килеп,
Әйткән идем, танышыйк.

Карлар ява, мин бәхетле,
Чөнки мин сиңа гашыйк.
Кыш бабай бүләк иткәндер,
Каршыма сине биреп.

Кояш чыкты, мин бәхетле,
Чөнки мин сиңа гашыйк.
Синең белән мин бәхетле,
Бәхетем ага ташып.

Кояш бата, мин бәхетле,
Чөнки мин сиңа гашыйк.
Күктә йолдызлар атыла,
Ә мин яратам шашып!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Илле биш.

Ике бишле алдым бүген,
Илле биш яшь үземә.
Көзгегә барып карадым,
Күренә егет күземә.

Елмаеп ул басып тора,
Әйтерсең егерме яшь.
Чал чәчләредә күренми,
Биреп булмый андый яшь.

Бик күпләр миннән сорыйлар,
Үзгәрмисең син ничек?
Йөрмәдем Аллага шөкер,
Тәмәке тартып, эчеп.

Эш эшләдем мин бик яшьтән,
Әнигә ярдәм иттем.
Унсигез яшь тулу белән,
Хезмәт итәргә киттем.

Утыз ел тулды тырышып,
Эшли башлаган көнгә.
Нефть табам, кара алтын,
Тыкшынмыйм мин бер кемгә.

Илле биш яшь, яшь мени ул?
Йөрәк бик яшь булганда.
Яшь калуның серләре дә,
Эчкерсез, тырыш булуда.

Ышанам мин үз-үземә,
Тартам тормыш арбасын.
Йөрәккәем типсен әле,
Туктамасын, армасын!
Улым ятим калмасын!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Ерак юл.

Ерак юлдан кайтып киләм,
Алда авыл күренә.
Туган авылым искә төште,
Ул күңелем түрендә.

Юллары яшел чирәмле,
Капка төбендә казлар.
Әбиләр бәбкәләр саклый,
Тәрәзәдән карый кызлар.

Авыл кызлары бик уңган,
Чибәр һәм дә бик гүзәл.
Мин әле бик яшь егет,
Ялам, кызарам, түзәм.

Бер кызга яратам диеп,
Бик килә дә әйтәсе.
Бик тә кырыс шул әткәсе,
Усал бигрәк әнкәсе.

Әбисе бар, аның белән,
Аралар безнең яхшы.
Ак әби ул булгангамы,
Йөзләре аның якты.

Искә төшерде бу авыл,
Минем яшьлек язымны.
Сагынам шул зифа буйлы,
Яшьли сөйгән кызымны!

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Көч тап...

Бүген сезгә кайгы килсә,
Иртәгә булыр җиңел.
Түзәргә, ышанырга кирәк,
Барысын, барысын җиңеп.

Раббым ярдәм ит, зинһар диеп,
Онытма тик әйтергә.
Бары Аның белән безгә,
Көч килә җирдә яшәргә.

Дәвам итә шулай тормыш,
Ак-кара, кара һәм ак.
Башыңны имә беркайчан,
Яшәү өчен көч син тап.

Ярдәм ит, синнән дә кыен,
Хәлдә калган кешегә.
Бу ярдәмең әйләнеп кайтыр,
Артып мең кат үзеңә.

Мескен булма, горур атла,
Алга барырга тырыш.
Тормыш шундый, ләкин кеше,
Барысын җиңәргә тиеш.

Бәхет-шатлыкны алыштыра,
Күз яшьләре, борчулар.
Тормыш шулай дәвам итә,
Килә шуңа ачулар.

Тынычланып, яшәвеңне,
Туган җирдә дәвам ит.
Үзеңнән соң бу дөньяда,
Якты истәлек калдырып кит!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Чит илнеке.

Акча булса евро булсын,
Киемнәр чит илнеке.
Чит илдә кояшта хәтта,
Яктырта икенче шикелле.

Машинаның иң зурысын,
Килә никтер аласы.
Тирә яктагылар күрсен,
Уйласын-бай баласы.

Европадан кайткан булсын,
Парфюм һәм шәраб.
Хатынныда читтән эзли,
Кешегә карап.

Кыланабыз без күп чакта,
Борынны күтәрәбез.
Матур яшәргә тырышып,
Буш вакыт үткәрәбез.

## Ашыкма сөйләргә сереңне.

Иң якын кеше ул диеп,
Ашыкма сөйләргә сереңне.
Ачылып, ышанып син аңа,
Калдырма уңайсыз үзеңне.

Сереңне ул сөйләр дустына,
Ә дусты үзенең дустына.
Бер тәүлек үтте дигәндә,
Сереӊ сер булмас беркемгә.

Күпертеп сереңне сөйләрләр,
Ул мондый, ул шундый диярләр.
Бер телдән, бер телгә йөртерләр,
Җаныңның иң нечкә кылына тиярләр.

Шуннан соң ышаныч югалыр,
Күңелең буш булып, ялгызы ул калыр.
Ашыкма сөйләргә сереңне,
Калдырма уңайсыз үзеңне!

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Туган тел.

И туган тел,
И матур тел диеп.
Тукай безгә язып калдырган,
Өстәп тагын шуны әйтер идем,
Бу тел безгә акыл да биргән.
Әннә диеп телебез ачылган,
Матурлыкны күргән күзебез.
Әти белән табигатьне күргәч,
Карап туя алмас күбебез.
Сокланганбыз туган җиребезгә,
Шулай матур бары бездә генә,
Кирәк бары күрә белү генә.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


# Әйләнеп кайтмас яшьлек.

Яшьлек әйләнеп кайтмас шул,
Чакырсак та бик озак.
Ул якларга бүтән юл юк,
Ишектә тора йозак.

Олы юлга аяк атлап,
Киткән көннәр гел истә.
Танышкан сөйгән яр белән,
Бер матур айлы кичтә.

Авыл тормышын шәһәргә,
Алыштырган вакытлар.
Брежнев дигән шәһәрдәге,
Очсыз-кырсыз урамнар.

Атна азагын сагынып көтү,
Авылга кайтыр өчен.
Бу ябык авыл малае,
Кайдан алгандыр көчен.

Чаба идек без җитешеп,
Тормышның тизлегенә.
Ничә гасырны без күрдек,
Шакыдык ишегенә.

Дөнья карарга диеп без,
Чыгып киттек туган авылдан.
Йөрәк тартты ләкин гел авылга,
Кичердек шул хәлне авырдан.

## Җиңү көнендә.

Җиңү көнен елап,
Шатлыктан каршы алдык.
Әти әйләнеп кайтмады,
Шулай без ятим калдык.

Сугышта һәлак булдылар,
Әтиләре күпләрнең.
Җиңү көнендә күрмәдек,
Язның матур күкләрен.

Әни шулай сөйли иде,
Күз яшьләрен ул сөртеп.
Гомерләре үтеп китте,
Кайтыр бәлки Әти диеп.

Кайтмадылар ун елдан соң,
Егерме, хәтта утыз.
Еллар үтте, өмет бетте,
Ялгыз без апа, ялгыз.

Ике кыз иделәр алар,
Көттеләр Әтиләрен.
Һәр ел саен Жиңү көне,
Чылатты яшьтән битләрен.

Каберен булмады хәтта,
Табып Әтиләренең.
“Хәтер китабы” битләрендә,
Таптык тик исемнәрен.

## Җитмеш төрле.

Җитмеш төрле булмаса да,
Бик күп минем һөнәрем.
Ялкауланып ятканым юк,
Эшләп үтә көннәрем.

Егет кеше эш эшләргә,
Ходайдан яратылган.
Төзек йорт булырга тиеш,
Ә миче агартылган.

Коймалары, капкалары,
Ерактан елмаялар.
Монда чын ир яши диеп,
Кычкырып ук торалар.

Кирәк икән аш пешерү,
Балык яки тәмле ит.
Барысы да бик җиңелдән,
Килеп чыга дуслар, ник?

Җавабы гади дусларым,
Башкарам күңел биреп.
Җиренә җиткереп эшлим,
Белгән догамны укып.

## Бергә булып.

Зарланмыйк әле дусларым,
Авыр диеп тормышларга.
Дөньялар тик тыныч булсын,
Каршы без сугышларга.

Зәңгәр күкләрне күрүе,
Түгелме дуслар бәхет?
Язын кошлар кайта, сайрый,
Күңелләргә рәхәт бит.

Өстәлләрдә хәләл ризык,
Тәмле чәй һәм туганнар.
Якын дуслар һәм күршеләр,
Бергә бүген җыелганнар.

Ул мондый, ул шундый диеп,
Зарланмыйк әле туганнар.
Ялгызлыкта кала беркөн,
Туганнардан туйганнар.

## Зәңгәр күк.

Зәңгәр күккә карыйм,
Нинди матурлык.
Булсын иде анда,
Йортым, торырлык.

Яшәр идем йөзеп,
Зәңгәр күкләрдә.
Йолдызларны күреп, эх,
Кочып, үбәргә.

Йөзәр идем күктә,
Болытлар кебек.
Җиргә төшәр идем,
Тамчылар булып.

Тагын менәр идем,
Парга әйләнеп.
Гизәр идем җир шарын,
Бәхетле булып.

## Мәңгелек түгел кешеләр.

Исән чакта бакыйлыкка,
Китүеңне истә тот.
Шөкер әйт һәрбер көнеңә,
Кичен дога укып ят.

Тетрәндергеч бу вакыйга,
Олы кайгы булмасын.
Бу югалту бер булачак,
Бүтән борчу килмәсен.

Мәңгелек түгел кешеләр,
Бу фани дөньяларда.
Арагыздан киткәннәрне,
Искә ал догаларда.

Җир йөзендә кеше вакытлыча,
Бакыйлыкка китә мәңгегә.
Ятим иттең диеп еламагыз,
Авыр яра алып күңелгә.

Хушлашырга иртә диеп,
Уйлыйлардыр бик күпләр.
Бары яхшы кешеләрне,
Көтәдер бәлки күкләр...

## Өстәлләрдә карлыган.

Чәй эчәбез кич белән,
Өстәлләрдә карлыган.
Күп эш бүген эшләнгән,
Шуңа да бик арылган.

Мунчадан соң бик тәмләп,
Чәй эчәбез, кич әйбәт.
Һавасы чиста, тынлык,
Авылда шундый рәхәт.

Туганнар, дуслар янда,
Кешеләр гади монда.
Эчкерсез, уңган, тырыш,
Барысы безгә таныш.

Моңсу китәсе килми,
Авыл безне җибәрми.
Шәһәргә кайткач та тынычлап,
Төннәрен йокы бирми.

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Бие әле.

Биик әле, бергәләшеп,
Башлар әйләнмәгәндә.
Калмасын үкенү булып,
Картайган көннәреңдә.

Бию яшәртә дуслар ул,
Бию канат, көч бирә.
Биегәннән соң дусларым,
Аяклар үзләре йөгерә.

Биегән кеше сәламәт,
Матур гәүдәле һәм төз.
Синдә дустым биергә өйрән,
Сәхнәгә чыгып чап тиз.

Сәхнә тактасын сындырма,
Түләсе булыр акчасын.
Биегәннәр очып йөрсен,
Биемәгәннәр аклансын.
(Аңлап, бии башласын).

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Рәнҗетмәгез.

Ялгыз диеп аны рәнҗетмәгез,
Гаебе юк аның, бу тормыш.
Табар парын, мин ышанам, чөнки,
Уңган үзе, үзе бик тырыш.

Ялгыз диеп аны рәнҗетмәгез,
Яклаучысы юк диеп, сез аны.
Үзегезнең бәхетегезне сез саклагыз,
Кирәк түгел сезгә калганы.

Минем белән булмас мондый хәл диеп,
Мактанмагыз, гайбәт чәчмәгез.
Юкка бәйләнмәгез, гаеп эзләп,
Ярыгызның канын эчмәгез!

Тормышыгыз бүген тулы, әмма ләкин,
Ниләр көтә икән иртәгә?
Тикшермәгез тирә яктагыларны сез,
Уйнамагыз тормыш белән һич тә!

Күз тимәсен, ялгыз калмагыз,
Ялгызлардан каргыш алмагыз.
Сак булыгыз, кеше яшеннән,
Ерак торыгыз давыл, яшеннән!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Җавап көтмим.

Кайтып киләм елда авылыма,
Хәлең ничек Әни, исәнме?
Җавап көтмим, Әнкәм инде ерак,
Көтәдер тик минем кайтканны.

Каберенә кайтып башны иям,
Рәхмәт әйтәм мин сиңа Әни.
Рәхмәт әйтәм, рәхмәт, рәхмәт, рәхмәт,
Рәхмәт Әни һәм рәхмәт Әти!

Бары да яхшы минем, син борчылма,
Урыннарың булсын оҗмахта.
Дөньялар тик тыныч түгел бүген,
Күп егетләр хәзер акопта.

Сугыш бара, үлеп кайта яшьләр,
Шуңа бары күңел борчыла.
Зыяратларда әнә күпме кабер,
Түзсен бары аналар гына.

Әтиемдә инде күптән бакый,
Күрә алмады безнең тормышны.
Кибетләргә үзе белән ала иде,
Булсын диеп, күпме тырышты.

Догаларны укып искә алам,
Әти-Әниемне көндә мин.
Яннарымда булсагызчы бер көн,
Кунак итәр идем сезне мин.

Кайтып киләм елда авылыма,
Әткәм-Әнкәм кабере янына.
Авыр туфракларыгыз җиңел булсын диеп,
Алам юлны кала ягына.

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Минеке син Татарстан.

Татарстан минем туган йортым,
Татар теле минем туган тел.
Кардәшләрем онытмагыз Татар телен,
Татар теле иң-иң матур тел.

Әти-Әни диеп без дәшәрбез,
Иң кадерле алар безнең өчен.
Әби-Бабай диеп хөрмәтләрбез,
Алар бик күп биргән безгә көчен.

Чит илләрдән үрнәкләр алырга,
Раббым безгә язмасын бер дә.
Үзебезнең динне, телне саклап,
Язсын иде яшәргә бергә!

Горурланып, без татарлар диеп,
Яшик дуслар Татар җирендә.
Бик күпләргә үрнәк без булырбыз,
Бирешмә син, бер дә җиңелмә!

## Сау бул Матур шәһәр.

Сау бул инде минем матур шәһәр,
Кайтып китәм туган авылга.
Яшьлегемне сиңа бүләк иттем,
Сыймый шул хәл хәзер башыма.
Дөнья куып, шау-шулы шәһәрдә,
Үтеп китте матур яшьлегем.
Искә төште таллы инеш буе,
Күзгә килде никтер яшьләрем.
Иртән иртүк торып эшкә чаптым,
Бик тырыштым алга атларга.
Онытылды шәһәр шау-шуында,
Авылымда калган атлар да.
Вакыт җитте менә хушлашырга,
Рәхмәт әйтәм ап-ак калага.
Нидер җитми, авыл сагындыра,
Охшап калдым сабый балага.
Биек йортлар, сәүдә нокталары,
Адым саен кибет, ресторан.
Затлы-затлы машиналар, тезелеп тора,
Йөзәр, меңнәр, шыгрым тулган урам.
Үзгәрешләр кертеп булмый хәзер,
Тормыш, гомер, бәхетем дә бәлки,
Шушы шәһәр белән бәйләнгән.
Шәһәр урамнарын ничә чакрым,
Җәяү йөреп, кат-кат әйләнгән.
Сау бул инде минем ап-ак калам,
Яхшылыклар бары теләп калам.
Вакытлыча булдык без шәһәрдә,
Авылыма юлымны мин алам,
Авылыма тугры булып калам!

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Кабан күле.

Кабан күленең төбендә,
Бик күп диләр мәрҗәннәр.
Аның бик күп икәнлеген,
Кемнәр икән күргәннәр?

Ышандырып сөйлиләр бит,
Бик кыйммәтле бу серне.
Төбенә төшеп эзләде,
Бик күпләр һәм буш менде.

Кабан күле җәлеп итә,
Бик күпләрне ни өчен?
Баерга бик тиз телиләр,
Бирмичә бер дә көчен.

Алай булмый шул дусларым,
Баеп була тир түгеп.
Төзелештә кирпич салып,
Яки игеннәр игеп.

## Балаларга киңәш.

Онытылып бара татар теле,
Күпләр күчте бүтән телләргә.
Ялгышмагыз газиз милләттәшләр диеп,
Теләк теләр идем мин сезгә.
Матур татар телен бүләк иткән,
Әти-әни, әби-бабайлар.
Балаларга без дә киңәш бирсәк,
Телебезне саклап калырлар.
(Яки бездән үрнәк алырлар,
Туган телсез, куркам, калырлар!)

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Атнага бер сәгать...

Атнага бер көн, бер дәрес,
Туган Татар теленә.
Барлык мәктәпләрдә бүген,
Шулай белем бирелә.
Онытыла Татар теле,
Бөек Тукай телебез.
Гаеплене мин эзләмим,
Гаепле без үзебез.
Татар теле ул тыйнак тел,
Кычкырмый мин, мин диеп.
Бу телне хөрмәтләүчегә,
Бирә белемне өеп.
Алыштырдык чит телләргә,
Бөек Татар телен без.
Киләчәктә ниләр көтә,
Әлегә без белмибез.
Аралашыйк дуслар бергә,
Чиста Татар телендә.
Балалар ишетеп үссен,
Бу матур телне көндә!

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Син Татар түгел инде...

Татарның көче нәрсәдә?
Онытмау туган телне.
Онытсаң син үз телеңне,
Син Татар түгел инде!

Татарның көче нәрсәдә?
Тырыш, эшчән булуда.
Әгәр син эш яратмасаң,
Син татар түгел инде!

Татарның көче нәрсәдә?
Яңа үрләр алуда.
Ялкауланып әгәр ятсаң,
Син Татар түгел инде!

Татарның көче нәрсәдә?
Тыйнак, гадел булуда.
Әгәр дә син ятсыз икән,
Син Татар түгел инде!

Татарның көче нәрсәдә?
Ислам динле булуда.
Динсез һәм син денсез булсаң,
Син Татар түгел инде!

Татарның көче нәрсәдә?
Хөрмәтләү өлкәннәрне.
Мин, мин, мин, мин,
Мин, мин дисәң,
Син татар түгел инде!

## Кадерлик әтиләрне.

Әтиләрнең кадерен белер өчен,
Никтер аны югалту кирәк.
Исән чакта әтием диеп әйтү,
Ниләр өчен икән бик сирәк?

Без үскәндә әтиләр керткән көчне,
Ник күрмибез, рәхмәт әйтмибез?
Әллә инде аннан башка да без,
Үсәр идек, җиңел үзебез?

Бер көн килә, әтиләр тыныч кына,
Китеп бара безнең арадан.
Шул көннән соң бары без аңлыйбыз,
Тормыш була икән карадан.

Күз яшьләре килә, ул булмагач,
Туган көне үтә бәйрәмсез.
Белгән булсак икән, белгән булсак?
Тормыш әтиләрсез бик ямьсез!

Кадерләрен белеп, әтиләрнең,
Әти диеп килеп кочыгыз!
Балалар да сезнең белеп торсын,
Аларның сез күзен ачыгыз!

Бабай диеп алар аралашсын,
Хәлен аның белеп торсыннар!
Безнең бабай иң-иң яхшы диеп.
Горурланып тормыш корсыннар!

## Әй, кешеләр...

Әй, кешеләр, ниләр кыланасыз?
Түгелә бит җиргә, күпме кан?
Ничә меңнәр кеше вафат диеп,
Ишетелә аткан саен җиргә матур таң.

Ниләр җитми?
Акча, мал, мөлкәтме?
Бәлки җитми җирләр, бакчалар?
Ничә буыннарга җитәрлек ич,
Сезнең талап җыйган акчалар!

Әй кешеләр,
Кеше түгелдер сез.
Нинди ана сезне тудырган?
Белем урынына, сезнең башка,
Нинди уйлар кертеп тутырган?

Иманлы бул балам димәгәндер,
Тәрбияне бер дә бирмәгән.
Шуңа күрә бүгенге бу адәмнәр,
Матурлыкны бер дә күрмәгән!

Әй кешеләр,
Әле бик соң түгел,
Туктатыгыз сугыш дигәнен.
Торгызыгыз өр яңадан барысын,
Йортлар, юллар җимерелгәнен.

Җиңүчеләр булмый сугышларда,
Кирәк безгә шуны аңларга.
Ни җитә соң тыныч, матур кичкә,
Иртән аткан матур таңнарга!

Әй кешеләр, әй кешеләр...

## Бәхеткә ничә яшь?

Бәхеткә ничә яшь икән?
Минекенә 15 яшь.
УЛ туган беренче көннән,
Тоям үземне бик яшь.

15 ел да үтеп киткән,
УЛымның туганына.
Буйга мине үтеп киткән,
Куанам булганына!

Әти өчен УЛ ярдәмче,
Дәвам итә буынны.
Туган көнең котлы булсын,
Кысам котлап кулыңны!

Иманлы бул диеп телимен,
Раббымнан саулык сорыйм!
Минем өчен син кадерле,
Бәхет мин сиңа телим!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


## Кыйммәтле.

Иң кыйммәтле Алмаз,
Ул миндә.
Йөрәгемнең,
Иң-иң түрендә.
Бәхетле бул балам,
Иманлы.
Исеңдә тот,
Тормыш буранлы.
Бирешмә син,
Бары алга бар.
Бик күп чакта,
Юллар була тар.
Үз юлыңны табып,
Син яшә.
Якын дуслар.
Булсын янәшә!
Акыллы бул,
Омтыл белемгә.
Укуларың,
Булсын бишлегә!

## Кирәкме PR?

Татарга PR кирәкме?
Кирәкме аңа толмач?
Татарстанда син яшә,
Татар син булып тугач!

Горурланып мин татар диеп,
Аралаш үз телеңдә.
Бүтән телләрне дә өйрән,
Өч, дүрт тел бел кимендә.

Югалмассың син беркайчан,
Бары алга барырсың.
Бүтәннәр ала алмаган,
Үрләрне син алырсың.

Татар теле, Тукай теле,
Иң-иң матур безнең тел.
Туганыңа татар булып,
Рәхмәтләр әйтә дә бел!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Ирләр өчен.

Хатын-кызлар ирләр өчен,
Күктәге йолдыз кебек.
Һәрберсе җемелди матур,
Атыла нурлар сибеп.

Хатын-кызлар ирләр өчен,
Күктәге кояш кебек.
Елмаялар өмет биреп,
Тылсымлы итеп көлеп.

Хатын-кызлар ирләр өчен,
Саклаучы йортның учагын.
Өстәлләрдә тәмле аш-су,
Безгә ни кирәк тагын?

Хатын-кызлар ирләр өчен,
Язның җылы яңгыры.
Яңгырдан соң сөендергән,
Матур салават күпере!

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Әти–Әни кирәк.

Әлбәттә Әниләр бик кирәк,
Әтиләрсез дә булмый.
Алардан башка булмавын,
Аңлылар бары аңлый!

Дөнья булгач, җир шарынча,
Гаилә түгәрәк булсын.
Үзебездән калган буын,
Безне искә гел алсын.

Минем Әни иң-иң яхшы,
Әти бик уңган диеп.
Оныкларга сөйләсеннәр,
Алар үссеннәр белеп.

Бары тырышлык күрсәтеп,
Яшәве җирдә җиңел.
Ялкауланып өйдә яту,
Безнең нәселдән түгел.

Әлбәттә Әни бик кирәк,
Аның янында Әби.
Әби янында Бабай да,
Бабай янында Әти!

## Онытып барабыз...

Берәр әйбер кирәк булса,
Чит илнекен алабыз.
Ватанчылык хисләрен дә,
Ник онытып барабыз?

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Үзебездә бар икән...

*WhatsApp* китте,
*Instagram* юк.
Ниләр эшләргә?
*Telegram* белән *VK*ны,
Кирәк эзләргә.
Мөмкин түгел пәрәвезсез*,
Бүген яшәргә.
Тәрбия бирер тагын кем,
Безнең яшьләргә?
Макдональдста озын чират,
Керерлек түгел.
Карап тордым да халыкка,
“Елады” күңел.
Үзебезнең ризык юкмы?
Юкмы үз эчемлекләр?
Кока кола белән бургер,
Булдымы шул азыклар?
Бәрәңгемнән аермасын,
Үзебезнең икмәктән.
Кыяр, помидор, кәбестә,
Бары безнең түтәлдән.
Татар ашларын ашарга,
Вакыт җиткәндер.
Өчпочмаклар, кыстыбыйлар,
Мичтә пешкәннәр!
Барысы да үзебездә,
Җитәрлек икән.
Уяндым коймак исенә,
Бүген мин иртән!

**Бөтендөнья пәрәвезе* - *Всемирная паутина*

**Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.**


## Сигез бала идек...

“Җидегән йолдыз” булып калдык,
Абыйны без “югалткач”.
Күңел әрнеп бик сызлады,
Шулай тормыш “елаткач”.

Сигез бала булып үстек,
Әти-Әни янында.
Абый бүген юк арада,
Ул салкын җир куенында.

Кырык көн дә үтеп китте,
Абыйны җирләгәнгә.
Түземлекләр, сәламәтлек,
Раббым бир, зинһар безгә!

Истә калган абыемның,
Кайтканы хезмәт итеп.
Чын артистлар кебек, матур,
Киез итекләр киеп.

Кешелекле, бала җанлы,
Иде ул безнең абый.
Бабай диеп кочагына,
Сыена иде сабый.

Балалар, оныклар диеп,
Ялны белми эшләде.
Оныклары бер-бер артлы,
Кулларыннан төшмәде.

Догалар барып ирешсен,
Абыемның рухына.
Якты истәлек калдырды,
Гаилә тарихына!

Электронная версия данного издания являются собственностью автора  Шибаева Равиля Файзиевича.


## Елның беренче көне.

Кемнең көне йоклап үтте,
Ә кемнеңдер эштә.
Кичә ашаган ризыклар,
Тынгы бирмиләр эчтә.

Яңа елны каршы алдык,
Бик мул өстәл артында.
Өстәлә инде авырлык,
Яшенә һәм картына.

Язлар җиткәч билне тагын,
Кирәк булыр эзлисе.
Матур фигуралар өчен,
Эшлисе дә эшлисе.

Ерагырак үлчәүләрне,
Алып куярга кирәк.
Саннарга риза булучы,
Калганнан кала сирәк.

Әле тагын берәр атна,
Көтәләр безне яллар.
Яңа Елга әзерләнгән,
Төрле-төрле салатлар.

“Оливье” дигән салатны,
Ел саен без ясыйбыз.
“Под шубой” һәм “мемоза”ны,
Атна буе ашыйбыз.

Анар беләзек* дигәнен,
Күбебез бик ярата.
Каз, тавык, пилмәннәр ашап,
Таңыбыз шулай ата.

**Гранатовый браслет*

Электронная версия данного издания являются собственностью автора Шибаева Равиля Файзиевича.


# Юкка алар димәк язылмаган...

Шигырьләрем Сезне берәр көнне,
Уйланырга мәҗбүр итсәләр?
Юкка алар димәк язылмаган,
Йөрәк аша бушка узмаган.
Берәр кеше әгәр ялгышуын аңлап,
Әти-Әнисенә юл тотса...
Күрешмичә үткән бик күп еллар,
Куркыныч төш булып артта калса...
Берәр кеше әгәр гафу ит диеп,
Иң беренче сүзен башласа...
Ничә еллар алар үпкәләрдә,
Гаепләр дә юк кебек ләбаса...
Туганлыкны, дуслык, тыныч тормышларны,
Өйрәнергә иде сакларга...
Әти-Әниләрнең, якыннарның,
Ышанычын иде акларга...
Барысы да дуслар, безнең кулда,
Туганнарга вакыт табыгыз.
Буш сүзләргә ачу, үпкә тотып,
Бу дөньяда ялгыз калмагыз!
*Туганнарга ачу тотмагыз!*

Рәхмәт!

**Сулар ага, вакыт сизелми үтә. Уйлы-гамьле еллар кичерелә, төрле юнәлешләрдә хезмәт куеп, күп кешеләр белән аралашып бай тормыш тәҗрибәсе туплана. Ике-өч ел эчендә ике шигырьләр җыентыгы: «Алабуга Татнефть Шибаев», «Ул минем өчен, ул минем көчем!» чыгып өлгергән. Бәлки шушы ике китап белән тынычланып калынган булыр иде әгәр өченче җыентыкны чыгаруга өндәгән туган-тумачалары, хезмәттәшләре, танышлары, дуслары булмаса. Алар чын күңелдән язылган шигырьләрне укып, авторга үзләренең хис-кичерешләрен аңлатып язмасалар, телефоннан шалтыратмасалар, бик шәп бу диеп күәтләп, рухландырып тормасалар. Автор шигырьләрен җыеп, туплап, киләчәккә өметләнеп эшен дәвам итә. Нәтиҗәдә, Аллага тапшырып өченче шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Укучыга тәкъдим ителәчәк бу китапка нефтьче-шагырьнең утыз еллык иҗаты туплап бирелә. Бу китапның басылып чыгуы, олы җанлы, кешенең эшен күрә белеп, хуплап торучы (бүтән милләттән булуына карамастан) җитәкче ярдәмендә насыйп булуы авторның төрле милләт вәкилләре, төрле катлам арасында абруе югары булуы турында дәлилләп, кешеләр белән аралаша белүен күрсәтә.**
**Автор Алескеров А.А. рәхмәтен белдерә!**

**2024 ел Алабуга**

**Печатная и электронная версия данного издания являются собственностью автора**
**Шибаева Равиля Файзиевича.**
**Её распространение без согласия автора запрещается!**